# КИТАПХАНӘ ХӘБӘРЛӘРЕ

Фәнни-гамәли журнал

Научно-практический журнал
1 (39) 2015

# БИБЛИОТЕЧНЫЙ ВЕСТНИК




## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕНӘ 150 ЕЛ

## НАЦИОНАЛЬНОЙ БИБЛИОТЕКЕ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН – 150 ЛЕТ

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә нигез салынуның 150 еллыгын бәйрәм итү турында**

Татарстан Республикасының мәдәни, мәгърифәти, фәнни, библиографик, методик үзәге һәм дәүләтнең төп китап саклау урыны буларак, Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең зур әһәмиятен билгеләп, **карар бирәм:**

1. 2015 елда Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә нигез салынуның 150 еллыгын бәйрәм итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бер ай эчендә Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә нигез салынуның 150 еллыгын бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты төзергә, шулай ук әлеге Указны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка чаралар күрергә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2014 ел, 19 декабрь
№ ПУ- 1156

БУ САНДА:
В НОМЕРЕ:

ГЫЙЛЕМ ХӘЗИНӘСЕ, ХӘТЕР САКЧЫСЫ... ....2
ХРАНИТЕЛЬНИЦА ДУХОВНОЙ СОКРОВИЩНИЦЫ НАРОДА ....5
Идарә • Администрация ....8
Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге • Отдел рукописей и редких книг ....10
Татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлеге • Отдел татарской и краеведческой литературы....12
Мәгълүмат-библиография бүлеге • Информационно-библиографический отдел....14
Документлар туплау бүлеге • Отдел комплектования документов....17
Республика китапханәләренә документлар туплау бүлекчәсе • Сектор комплектования библиотек республики ....19
Фәнни-методик бүлек • Научно-методический отдел....21
Чит телләрдәге әдәбият бүлеге • Отдел литературы на иностранных языках....25
Сәнгать бүлеге • Отдел искусств....28
Укучыларны теркәү һәм статистика бүлеге • Отдел регистрации и статистики ....31
Файдаланучыларга хезмәт күрсәтү бүлеге • Отдел обслуживания пользователей....32
Күргәзмәләр һәм мәдәни программалар бүлеге • Отдел выставок и культурных программ ....33
Китапханәара абонемент һәм документларны электрон юл белән алдыру бүлеге • Отдел межбиблиотечного абонемента и электронной доставки документов ....35
Документларны фәнни эшкәртү һәм каталоглар оештыру бүлеге • Отдел научной обработки документов и организации каталогов....37
Китап саклау бүлеге • Отдел основного книгохранения ....39
Вакытлы матбугат бүлеге • Отдел периодических изданий....41
Халыкара һәм төбәкара китап алмашу бүлеге • Отдел международного и межрегионального книгообмена....43
Редакция-нәшрият бүлеге • Редакционно-издательский отдел....45
Мәгълүмати һәм китапханә технологияләре бүлеге • Отдел библиотечных и информационных технологий ....48
Автоматлаштыру-компьютерлаштыру бүлеге • Отдел автоматизации....50
Маркетинг бүлеге • Отдел маркетинга ....52
Китап укуга җәлеп итү һәм тышкы элемтәләр бүлеге • Отдел продвижения книги и внешних связей....53
Патентлар бүлеге • Патентный отдел ....55
Китапларны чистарту һәм реставрацияләү бүлеге • Отдел гигиены и реставрации книг ....57
Кадрлар белән эшләү һәм эшчәнлекне документлар белән тәэмин итү бүлеге • Отдел работы с кадрами и документационного обеспечения деятельности....59
Исәп-хисап бүлеге • Бухгалтерия....60
Хуҗалык-эксплуатация хезмәте • Хозяйственно-эксплуатационная служба ....61
Котлаулар • Поздравления ....62

КИТАПХАНӘ ХӘБӘРЛӘРЕ
№ 1 (39) 2015

ФӘННИ-ГАМӘЛИ ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ ТАРАФЫННАН 1996 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП НӘШЕР ИТЕЛӘ. ЕЛГА 2 ТАПКЫР ТАТАР ҺӘМ РУС ТЕЛЛӘРЕНДӘ ЧЫГАРЫЛА.

БАШ МӨХӘРРИР
Р.И. ВӘЛИЕВ

РЕДКОЛЛЕГИЯ:
С.Р. ҖИҺАНШИНА,
И.Г. ҺАДИЕВ
(БАШ МӨХӘРРИР УРЫНБАСАРЫ),
Р.Ә. ХӨСӘЕНОВА
(ҖАВАПЛЫ СӘРКЯТИБ),
А.Р. ГАБДЕЛХАКОВА,
А.Җ. ЗАҺИДУЛЛИН

БИБЛИОТЕЧНЫЙ ВЕСТНИК
№ 1 (39) 2015

НАУЧНО-ПРАКТИЧЕСКИЙ ЖУРНАЛ

ИЗДАЕТСЯ НАЦИОНАЛЬНОЙ БИБЛИОТЕКОЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН С МАЯ 1996 ГОДА. ВЫХОДИТ 2 РАЗА В ГОД НА ТАТАРСКОМ И РУССКОМ ЯЗЫКАХ.

ГЛАВНЫЙ РЕДАКТОР
Р.И. ВАЛЕЕВ

РЕДКОЛЛЕГИЯ:
С.Р. ЗИГАНШИНА,
И.Г. ХАДИЕВ
(ЗАМ. ГЛАВНОГО РЕДАКТОРА),
Р.А. ХУСАИНОВА
(ОТВ. СЕКРЕТАРЬ),
А.Р. АБДУЛХАКОВА,
А.З. ЗАГИДУЛЛИН

*Казан шәһәренең үзәгендә, чал тарихлы университетның мәрмәр колонналы төп бинасына каршы диярлек урнашкан, тышкы күренеше белән күпләрне таң калдыра торган, эченә керсәң, бай рухи азык һәм бихисап акыл-гыйлем алырлык йорт – Татарстанның төп Китап Сарае – республикабызда яшәүчеләрнең күбесенә таныш. Милли китапханә дип аталучы бу йортта һәркемгә, нинди милләттән, кайсы илдән, ничә яшьтә, нинди һөнәр иясе булуына карамастан, китапханә хезмәте күрсәтәләр. Югары һәм махсус белем бирүче уку йортларында, мәктәпләрдә белем алучыларны, укытучыларны, галим-голәманы аеруча күп кабул итәләр биредә. Китапханәгә килүченең максаты – үзенең нинди дә булса китапка, әдәбиятка, мәгълүматка булган ихтыяҗын канәгатьләндерү.*

*Хәзерге вакытта Милли китапханәгә йөрүчеләрнең күбесе, нигездә, һөнәренең үзенчәлеге, эш юнәлеше, аерым бер уку программасы буенча таләп итела торган әдәбиятка тартыла. Китапханәнең үткәне, ул урнашкан ике катлы гүзәл бинаның тарихы, китапханәдәге төрле бүлекләр, аларның ни белән шөгыльләнүләре, киләчәккә планнары, нинди өстәмә хезмәтләр күрсәтелүе, китапханә эшчәнлегендәге яңалыклар, күзгә бик ташланмый торган эчке үзгәрешләр белән кызыксынучылар саны аз түгел. Бу файдалы һәм әһәмиятле мәгълүматлардан бихәбәр булганнарга китапханәнең Интернеттагы сайтына күз салырга тәкъдим итәбез. «Китапханә хәбәрләре» журналын укучылар исә түбәндәге язмага да битараф булмаслар.*

# ГЫЙЛЕМ ХӘЗИНӘСЕ, ХӘТЕР САКЧЫСЫ...

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе статусын (бу атама Дәүләт китапханәсе дигәнгә бәрабәр) йөртүче китапханәнең оешуына быелның гыйнварында 150 ел тулды. Ул Россиядәге һәркем файдалана ала торган җәмәгать китапханәләренең иң әүвәлгеләреннән санала, башлангычы Казан шәһәрендә 1865 нче елның 10 (24) гыйнварында ачылган Казан җәмәгать китапханәсенә барып тоташа. Ә аның нигезен танылган китап сөюче (библиофил) Иван Алексеевич Второвның шәхси китапханәсе тәшкил иткән. Кечкенә генә җәмәгать китапханәсе шушы гасыр ярым вакыт эчендә Россиядәге иң зур милли китап хәзинәләренең берсенә әверелде.

1844 елда «Казан губернасы хәбәрләре» газетасының бүлек мөхәррире, әдәбият белгече, археолог һәм этнограф Николай Иванович Второв Казаннан Петербургка хезмәткә күчкәндә, әтисе Иван Алексеевич гомере буе туплаган, 1908 нөсхәдән торган китапханәне шәһәргә бүләк итеп калдырган. Бу китаплар бәйләмнәрдән киштәләргә күчеп, җәмәгать китапханәсен тәшкил иткәнче 20 ел вакыт үтеп киткән. Бер урыннан икенчесенә күчерелә-күчерелә шактый гына томнар югалган. Ул заманнарда да гади халыкка игелек-изгелек эшләүдән тайчыну, рухи кыйммәтләргә битараф карау җитәкче аппарат вәкилләре, «йомшак урындыкларда» утыручылар өчен ят гамәл булмаган икән. Ниһаять, күп киртәләр алып ташланып, 1865 елның гыйнварында Казан шәһәр җәмәгать китапханәсе ачылган. Моңа кадәр университетта, Духовная семинариядә китапханәләр эшләгән булса да, шәхси кулларда китаплар сакланса да, җәмәгать китапханәсе үз укучыларын тапкан, фондлары да елдан-ел үсә барган. Бик озак еллар Казанның беренче бушлай җәмәгать китапханәсен «Второвлар китапханәсе» дип тә атаганнар. Әйтергә кирәк, аталы-уллы Второвлар – шул чорның зыялы һәм күренекле кешеләреннән булып, Казан шәһәре һәм Идел буе төбәкләрендә үзләреннән соң тирән эз калдырган шәхесләр.

Ул заманнарда китапханә, нигездә, «өлкән туган»га гына хезмәт иткән. Ә китапны гомере буена җан юлдашы иткән татар халкы шәхси куллардагы,



мәдрәсәләрдәге, соңрак җәмгыяте хәйрияләр оештырган китапханәләрдән файдаланган. Шанлы дәүләтләре бар чакта китапханәләре гөрләп торган халыкка, дәүләтеннән мәхрүм калгач, җәбер-золым, милли-дини изү астына эләккәч, әлбәттә, җәмәгать китапханәләре оештыру хокукы да бирелмәгән. Ләкин XIX гасырның 70–80 нче елларында ук мондый уй-фикерләр, өмет-хыяллар белән янып йөрүчеләр була. Аларны тормышка ашырырга 1905–1907 еллардагы инкыйлаб мөмкинлек бирә, аның нәтиҗәсендә халык китапханәләре оештыруда зур урын тоткан татар хәйрия һәм төрле мәдәният-мәгариф җәмгыятьләре барлыкка килә. Күренекле татар журналисты, тел галиме һәм җәмәгать эшлеклесе Әхмәдһади Максуди инициативасы һәм тырышлыгы белән 1906 елның башында «Көтепханәи исламия» – Казан шәһәр җәмәгать китапханәсенең мөселман филиалы ачыла. Ул башта Печән базарындагы Кәримевләр йортында, аннары «Болгар» кунакханәсенең өченче катында урнаша. Беренче эш көннәреннән үк шәһәрдә яшәүчеләрнең «Көтепханәи исламия» белән кызыксынулары зур булган, елдан-ел көчәя барган. Моны укучыларга хезмәт күрсәтү һәм китаплар, газета-журналлар бирү турында безнең көннәргә кадәр сакланган мәгълүматлар раслый.

1906 елның 2 гыйнварында Казанда ачылган татар китапханәсе үз эшен уңышлы дәвам иткән. Советлар хакимияте урнашкач, 1920–1929 нчы елларда китапханә «Мәркәз шәрык көтепханә-музее» исемендә эшләп килгән. 1920 нче еллар ахыры – 1930 нчы еллар башында китапханә төрле фәнни оешмаларга таркатылган. Нәтиҗәдә, хәзерге вакытта, «Мәркәз шәрык көтепханә-музее» фондының борынгы гарәп һәм фарсы кулъязмаларыннан, газета һәм журналларның еллык төпләмнәреннән, күпсанлы башка китаплардан гыйбарәт булган зур бер өлеше Казан университеты Фәнни китапханәсендә, бер өлеше Татарстан Матбугат архивында һәм аз күләмдәге бер өлеше Татарстан Милли китапханәсендә саклана.

* * *

1919 елда Казан шәһәр җәмәгать китапханәсен шәһәр үзәгенә урнашкан ике катлы матур бинага – элекке Зинаида Ушкова йортына – күчерәләр. Бу бина бүген дә Китап Сарае вазифасын үти. Ул XX йөзнең башында архитектор К.Л. Мюфке проекты буенча төзелгән.

Менә сез тышкы яктан сәнгати-архитектур алымнарның бик күп төрләрен мул куллanып бизәлгән, зур тәрәзәләре, көмешсыман гөмбәзчеге, турыпочмаклы һәм түгәрәк балконнары, балконнарның челтәрле кырлары белән үзенчәлекле бер сәнгать һәйкәле булган бинаның әүвәлге авыр ишекләрен ачып эчкә үтәсез, Сарайның тыныч, серле һәм гаҗәеп дөньясына чумасыз. Сезне ишек тоткаларына, баскыч култыкларына, диварларга, тәрәзә пыялаларына ясалган кошлар, җәнлекләр, әкият каһарманы-аждаһалар каршы ала, идәннәргә, түшәмнәргә һәм диварларга төшерелгән үсемлек, чәчәк-яфрак бизәкләре күзне иркәли. Монысы – кытай-япон стилендә эшләнгән вестибюль. Бамбук таяклары белән бер-берсеннән аерылып торган рәсемнәрдә – бу халыклар көнкүрешен чагылдырган күренешләр. Зур тантаналар залы (хәзер зур уку залы) үзенең күзне камаштырырлык аклыгы һәм алтын йөгертелгән, ампир стилендәге сынлы бизәкләре белән ялтырап тора. Ашханә (хәзер техник әдәбият бүлекчәсе) кара агачтан эшләнгән, оркестр өчен югары күтәртеп махсус сәндерә ясалган. Кунаклар бүлмәсендә һәм йорт хуҗасының бүлмәсендә (мәгълүмат-библиография бүлеге һәм гуманитар фәннәр әдәбияты бүлекчәсе) искиткеч шәп каминнар. Залларның берсе сталактитлы мәгарә рәвешендә ясалган, бер дивары уелып, аквариум куелган. Мәгарәнең уртасында элек фонтан атып торган, аның идәндәге эзләрен бүген дә күрергә мөмкин. Түгәрәк балконлы почмак бүлмәнең (хәзер күргәзмәләр залы) бизәлеше мавритан стиленә карый, балконга чыгу юлындагы түгәрәк бүлмә мәчет манарасын хәтерләтә, анда тавыш бик яхшы яңгырый. Ишекләргә сырлап үсемлек

орнаментлары, тоткаларына гарәп язуы элементлары төшерелгән. Рәссам-архитектор шул дәрәҗәдә фантазиягә бай кеше булган ки, йортта бүлмәләр бик күп булса да, бизәкләр, сырлар, төсләр бер дә кабатланмый. Ике бүлмәне тоташтыручы ишекнең ике ягы ике төрле, бер бүлмәгә чыга торган берничә ишек уртак бер стильдә ясалган. Йортны бизәүдә мәрмәр һәм бронза, кара агач, төсле пыяла, йөгертелгән алтын, ифрат күп көзге кулланылган.

Бизәлештәге үзенчәлекләр турында бик күп сөйләргә мөмкин булыр иде. Гомумиләштереп шуны әйтәсе килә: бизәлештәге һәм эшләнештәге зәвыклылык, сәнгать бөтенлеге рәссамга, бинаны төзүчеләргә ихтирам һәм соклану уята.

* * *

Инде Милли китапханәнең бүгенге тормышына күчик. Аның китап укучыларга тиешле дәрәҗәдә хезмәт күрсәтүен, өстәмә уңайлыклар тудыруын ике дистәдән артык бүлек һәм бүлекчә тәэмин итә. Мәдәният хезмәткәрләренә түләнә торган аз хезмәт хакына карамыйча, эшләрендә бернинди тоткарлык тудырмыйча, «китап укучы һәрвакыт хаклы» дигән сүзләрне үзләренә кагыйдә итеп алган тәҗрибәле-оста һәм белемле-тырыш 230 дан артык хезмәткәр эшли биредә.

Китаплар туплау, аларны эшкәртү-каталоглаштыру, саклау бүлекләренең вазифалары турында исемнәре үк әйтеп тора. Уку залы (ул гуманитар фәннәр әдәбияты, хокук әдәбияты һәм техник әдәбият бүлекчәләреннән тора), башка китапханәләр белән китаплар алышып-бирешеп торучы китапханәара абонемент эшли. Китапханәдә китапларны, газета-журнал мәкаләләрен, һәртөрле информацияне эзләп табу эшләрен автоматлаштыру һәм компьютерлаштыру бүлеге яңа технологияләргә нигезләнеп елдан-ел камилләштерә. Мәгълүмат-библиография бүлегендә төрле фән тармакларына караган библиографик мәгълүматлар, белешмә-консультацияләр алырга мөмкин. Татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлегендә татар телендәге, Татарстан һәм татарлар турында башка телләрдәге һәм туган якны өйрәнүгә караган китаплар, милли библиография һәм матбугат материаллары, башка басмалар тупланган.

Борынгы татар кульязма һәм иске басма китаплары, татар тарихына караган әүвәлге документлар һәм фотосурәтләр, гарәп һәм латин язуындагы татар газета-журналлары, китапханәгә нигез салган Второв китаплары коллекциясе, 1917 елга кадәр басылган, сирәк очрый торган рус китаплары, хәзерге заманның сирәк китаплары, язучыларның китапханәгә бүләк иткән имзалы китаплары кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге киштәләрендә урын алган. Милли китапханәнең икенче бинасында (Карл Маркс урамы, 36 нчы йорт) вакытлы матбугат, чит телләрдәге әдәбият, фәнни-методик, патентлар, китапханә һәм мәгълүмати технологияләр, халыкара һәм төбәкара китап алмашу бүлекләре, өченче бинасында (Театр урамы, 5 нче йорт) сәнгать, редакция-нәшрият, китапларны чистарту һәм реставрацияләү бүлекләре урнашкан.

Бүлекләрнең барысы да халыкның китапка, язма сүзгә, мәгълүматка булган ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм биредәге рухи байлыкны киләчәк буыннар да файдаланырлык итеп саклау бурычын үти.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе – татар мәдәниятен таныту үзәге, татар китабын һәм республикабыз турындагы әдәбиятны туплау, саклау, тарату мәсьәләләре белән максатчан рәвештә шөгыльләнә торган, Россиядәге, якын һәм ерак чит илләрдәге татар укучыларына хезмәт күрсәтүче китапханәләр белән традицион элемтәләре булган бердәнбер зур китапханә. Аның фондларында 3 млн. 300 мең нөсхәгә якын һәртөрле басмалар, шул исәптән татар телендәге 120 мең, чит телләрдәге 82 мең китап тупланган. Милли китапханә хезмәтләреннән ел саен 35 меңнән артык китап укучы файдалана, аларга 1,5 млн.га якын китап һәм башка төрле басмалар бирелә.

* * *

150 еллык олуг юбилей мөнәсәбәте белән язылган бу кыска мәкаләдә китапханәнең проблемалары яктыртылмады. Татарстан хөкүмәте, мәдәният министрлыгы, китапханә җитәкчелеге аларны яхшы белә, уңай хәл итү юнәлешендә эшли. Республикабыз Милли китапханәсенең 150 еллыгыннан соң киләчәк юбилейларын (155, 160 еллыклар) каршылаганда мөһим проблемаларның күбесе (шул исәптән, яңа бина төзү мәсьәләсе дә) хәл ителгән булыр, алдагы зур бәйрәмнәрне дә китап сөючеләрдән, мәгълүмат эстәүчеләрдән аерылмыйча, фән, мәдәният, мәгариф, каләм әһелләре китапханә белән бәйләнешләрен өзмичә, бергәбергә үткәрербез дигән өмет-ышанычлар белән калабыз.

# ХРАНИТЕЛЬНИЦА ДУХОВНОЙ СОКРОВИЩНИЦЫ НАРОДА

Колесо истории стремительно вращается, вовлекая каждого из нас во все новые и новые события… Незаметно пролетел год 2014 – Год культуры, настал год 2015, объявленный в РФ Годом литературы. И вновь мы приобщаемся к миру великого творения человечества – Литературе и Книге. А значит, все наши взоры будут обращены на её величество Библиотеку – бессменную хранительницу духовной сокровищницы народа!



Такова уж её миссия – сохранять и передавать будущим поколениям всё самое ценное в духовной культуре. А миссия национальных библиотек уникальна вдвойне – это главное звено, обеспечивающее доступ к отечественным и мировым информационным ресурсам, в том числе и национальным, это условие формирования и сосуществования гражданского общества. В Татарстане роль Национальной библиотеки, чей 150-летний юбилей отмечается в 2015 году, особенная, что обусловлено наличием в республике большого количества различных этнических и этнокультурных групп, проживанием на её территории народов-носителей основных мировых конфессий. В условиях многонационального государства важным стабилизирующим фактором выступает национальная культура как основа межнационального общения. И библиотека становится



той доступной и открытой площадкой, на которой и происходит данный диалог культур.

Республика Татарстан имеет давние книжные и библиотечные традиции, закономерным продолжением которых стало основание в 1865 году в Казани Публичной библиотеки. Её основу составила коллекция местного библиофила и краеведа Ивана Алексеевича Второва, насчитывающая 903 названия и 1908 томов книг, периодических изданий, подаренная городу его сыном Н.И. Второвым – литератором, археологом и этнографом с целью организации общественной библиотеки.

В 1906 году в Казани открывается «филиальное отделение Публичной библиотеки» для мусульман, которое становится одним из татарских просветительских центров России того времени. В XX веке библиотека пережила ряд переименований: в 1917 году – Центральная губернская библиотека, а затем в 1923 году – Центральная городская библиотека. В 1920 году ей присваивается имя В.И.Ленина. «Филиальное отделение» для мусульман в 1919 году реорганизуется в городскую библиотеку № 5, а в 1922 году – в Центральную восточную библиотеку-музей им. М.Вахитова; в 1929 году она объединяется с Центральной городской библиотекой. В 1934 году Центральная библиотека реорганизуется в областную и в 1941 году – в республиканскую, возложив на себя функции центра методического руководства библиотечным делом в республике. В 1965 году утверждается новый Устав библиотеки, в соответствии с которым библиотека получает статус научной.

В 1991 году, на гребне кардинальных социально-политических изменений в стране, библиотека приобретает статус Национальной библиотеки.

Сегодня Национальная библиотека – главное государственное книгохранилище национальной и республиканской, российской и зарубежной печати, многофункциональное библиотечно-информационное и научно-исследовательское учреждение, культурный, библиографический и методический центр. Библиотека является центром пропаганды культуры татарского народа, единственной публичной библиотекой мира, выполняющей функции комплектования, сохранения и распространения татарской книги и литературы о республике. Библиотечный фонд насчитывает более 3 млн300 тыс. экземпляров документов, в том числе 120 тыс. документов на татарском языке.

Национальная библиотека РТ осуществляет такие направления деятельности, как информационное обслуживание, автоматизация библиотечно-библиографических процессов, научное и методическое руководство деятельностью муниципальных библиотек республики и др. Коллектив библиотеки насчитывает более 230 работников, из них 180 – специалисты с высшим и средним специальным образованием. Организация эффективного обслуживания пользователей библиотеки обеспечивается прежде всего качественной структурной организацией библиотеки. В библиотеке функционируют 23 отдела, непосредственные услуги пользователям библиотеки оказывают такие отделы, как отдел искусств; литературы на иностранных языках; периодических изданий; редких книг и рукописей; татарской и краеведческой литературы; межбиблиотечного абонемента; патентный; информационно-библиографический; обслуживания пользователей; выставок и культурных программ. Актуальную информацию с использованием современных компьютерных технологий предоставляют пользователям библиотеки Центр информации по культуре и искусству, Республиканский центр правовой информации,

виртуальный читальный зал, Интернет-центр и др.

«Статус библиотеки как главного республиканского библиотечного центра закреплен законами РТ и федеральными законами. Ведущая роль Национальной библиотеки определяется традиционностью её центрального положения среди библиотек республики, высоким уровнем полноты комплектования, качеством и разнообразием библиотечных услуг, общедоступностью для различных категорий потребителей».

Национальная библиотека Республики Татарстан – авторитетное в своей области научное учреждение. Библиотека известна в регионе и за его пределами как исследовательское учреждение, привлекающее к своим научным разработкам представителей Казанского (Приволжского) федерального университета, Казанского государственного института культуры, ведущих специалистов Института языка, литературы и искусства АН РТ, Архива печати РТ, Научной библиотеки КФУ им. Н.И.Лобачевского и других заинтересованных организаций. В стенах Национальной библиотеки обсуждаются законодательные акты, программные документы, планы НИР в области библиотечного и книжного дела, библиографии, программы научных исследований, нормативных и регламентирующих деятельность библиотеки документов. Самостоятельным направлением выступает формирование редакционно-издательской политики, подготовка и рецензирование планируемых к опубликованию изданий.

Тематика научно-исследовательской работы библиотеки представлена такими научными направлениями, как «книга и читатель в системе информационного обеспечения Республики Татарстан»; «библиотечное дело и библиография: история и современность»; «проблемы информационного обеспечения пользователей»; «исследование проблем библиотечной профессии». Помимо собственных специалистов, к исследовательской работе привлекаются и коллеги из отдела рукописей и редких книг Научной библиотеки им. Н.И.Лобачевского К(П)ФУ, отдела рукописей и текстологии Института языка, литературы и искусства АН РТ, Архива печати РТ, Республиканской детской и Республиканской юношеской библиотек, Республиканского медицинского библиотечно-информационного центра, Казанского государственного института культуры и др. Результаты НИР отражаются в содержании научно-практических конференций, сборниках материалов, библиографических указателях и др.

Активная научно-исследовательская деятельность библиотеки определила учреждение в 1996 году на её базе издательства «Милли китап». Издательство специализируется на подготовке справочных изданий по библиотечному делу и библиографии, книговедению и информатике; профессиональной периодической печати; библиографических указателей литературы, посвящённых различным аспектам культуры республики; сборников научных материалов по истории библиотек края; методических материалов в помощь массовой и информационной деятельности библиотек; научных и научно-популярных изданий, освещающих страницы истории и культуры народов Татарстана; научно-практического журнала «Библиотечный вестник» и др. Осуществляет данное направление работы редакционно-издательский отдел.

Национальная библиотека позиционирует себя не только как авторитетное информационное учреждение, но и крупный просветительский, образовательный центр Республики Татарстан. Она является базовой площадкой для организации и проведения культурных, образовательных и других социально ориентированных мероприятий различного уровня. Открытость, быстрое реагирование на новации, стремление к взаимодействию в информационной и библиотечной сферах повышают востребованность Национальной библиотеки Республики Татарстан.

Примечательно, что Год литературы в Республике Татарстан пройдет также под флагом празднования 150-летия старейшей библиотеки нашей республики. О значимости данного события для общественности республики свидетельствует Указ Президента РТ «О подготовке и проведении мероприятий, посвященных празднованию 150-летия Национальной библиотеки Республики Татарстан», согласно которому образован оргкомитет из числа представителей профильных министерств, СМИ, творческих союзов, учреждений науки и образования. Это не только дань уважения опыту и вкладу библиотеки в культурное и научное развитие региона, но и понимание её перспектив как неотъемлемого ресурса социально-экономического и гуманистического развития нашей республики.

# КИТАПХАНӘ ИДАРӘСЕ | АДМИНИСТРАЦИЯ БИБЛИОТЕКИ

Милли китапханә – гражданнарның мәгълүмат алуга ирекле һәм тигез хокукларын тәэмин итү, аларның мәгърифәткә, мәдәнияткә, рухияткә бәйле ихтыяҗларын үтәү өчен камил шартлар тудыру, илкүләм һәм дөньякүләм мәдәни кыйммәтләргә якынайту максатларын алдына куеп эшләүче мәдәният һәм мәгълүмат оешмасы.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе идарәсе үз эшчәнлегендә Россия һәм Татарстан Конституцияләренә, федераль һәм республика законнарына, РФ һәм ТР Президентлары указларына, ТР Мәдәният министрлыгы боерыкларына, ТР Дәүләт Советы карарларына, Гамәлгә куючысының күрсәтмәләренә, китапханәнең Уставына һәм башка норматив документларга таяна.

Идарә белгечләре китапханәнең структурасын һәм штат расписаниесен, норматив һәм башка эчке документларын эшли, раслый, китапханә эшенең торышын тикшереп тора.

Алар бербөтен оешма буларак китапханәнең якын һәм ерак киләчәккә планнарын билгеләләр, көндәлек эшчәнлеген оештыралар. Милли китапханәнең финанс, хуҗалык, методик, фәнни эшчәнлеген көйләү һәм аның белән идарә итү, үсеш стратегиясен билгеләү, эш дәвамында килеп чыккан һәртөрле ситуацияләрне анализлау, заманча таләпләргә тиз арада җайлашу, китапханә хезмәтләреннән файдаланучыларга да, хезмәткәрләргә дә тиешле шартлар тудыру идарә хезмәткәрләренә йөкләнгән. Мөһим эш юнәлеше булып торучы халыкара хезмәттәшлек тә китапханә идарәсенең күз уңында торырга тиеш.

Идарә составын тәшкил итүчеләр:

– китапханә директоры Җиһаншина Сөембикә Разил кызы;

– директорның фәнни эшләр буенча урынбасары Һадиев Ирек Габделхәй улы;

– директорның китапханә эше буенча урынбасары Җәлалова Лилия Равил кызы;

– директорның үсеш һәм гомуми мәсьәләләр буенча урынбасары Пичугина Галина Валентиновна.

Национальная библиотека – крупное культурное и информационное учреждение, осуществляющее комплекс мероприятий по обеспечению прав граждан на свободный и равный доступ к информации, созданию оптимальных условий для удовлетворения их образовательных, культурных и духовных потребностей, приобщению к ценностям отечественной и мировой культуры.

Администрация Национальной библиотеки РТ в своей деятельности руководствуется Конституцией Российской Федерации, федеральными и республиканскими законами, указами и распоряжениями Президентов РФ и РТ, приказами Министерства культуры РТ, постановлениями и распоряжениями Государственного Совета РТ, решениями Учредителя, Уставом и другими нормативными актами.

Специалисты подразделения разрабатывают и утверждают структуру и штатное расписание библиотеки, нормативные и плановые документы, осуществляют мониторинг состояния библиотечной работы.

Сотрудники данного подразделения обеспечивают перспективное и текущее планирование и организацию деятельности всей библиотеки как единого организма. Координация и управление финансовой, хозяйственной, методической, научной деятельностью Национальной библиотеки, выработка стратегии ее развития, анализ различных производственных ситуаций, мобильное реагирование на требования современной теории и практики, создание необходимых условий для пользователей библиотеки возлагается на сотрудников администрации. Важным направлением деятельности библиотеки является международное сотрудничество, что также является объектом деятельности администрации библиотеки.

В ее состав входят:

– директор библиотеки Зиганшина Сююмбика Разильевна;

– заместитель директора по научной работе Хадиев Ирек Габделхаевич;

– заместитель директора по библиотечной работе Залялова Лилия Равилевна;

– заместитель директора по развитию и общим вопросам Пичугина Галина Валентиновна.



# КУЛЪЯЗМАЛАР ҺӘМ СИРӘК КИТАПЛАР БҮЛЕГЕ

1970нче еллар башында китапханәдә сирәк китаплар бүлекчәсе(секторы) оештырыла. Әлеге секторның эшен оештыруда китапханәчеләр Д.З.Гарифуллина, Т.А.Волонкович, Н.С.Митрофанова, Э.С. Атнагулов күп көч куя. 1992 елда шушы сектор нигезендә кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге оешты. Хәзерге вакытта бүлек татар һәм көнчыгыш әдәбияты, рус һәм көнбатыш әдәбияты бүлекчәләреннән гыйбарәт.

Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге фондында 60 меңгә якын сирәк, кыйммәтле һәм аерым әһәмияткә ия булган документлар тупланган.

Бүлекнең беренче мөдире галим-археограф Р.Ф.Мәрданов булды, ә 1999 елдан хәзерге көнгә кадәр бүлек мөдире вазыйфасын А.Ж.Заһидуллин үти.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе директорының фәнни эшләр буенча урынбасары И.Г.Һадиев та үзенең китапханәдәге хезмәт юлын нәкъ менә шушы бүлектә башлап җибәрде.

Төрле елларда кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә өлкән һәм тәҗрибәле китапханәчеләребез Н.Ә.Асылкаева, З.З.Вәлиуллина, А.Ф.Мәхмүтова, Л.П.Юревич,Т.И.Фомина эшләде. Бүген югары квалификацияле белгечләребез И.Х.Әхмәтшина, А.Х.Гәрәева, Й.К.Сабитова, Г.Р.Хөсәенова хезмәт итә.

Рус һәм көнбатыш әдәбияты бүлекчәсе мөдирләре: 1996 елга кадәр – Э.С.Атнагулов, 1998 – 2010 елларда – Г.Г.Шаһиәхмәтова, 2015 елдан – Р.К.Юнысова. Алар белән беррәттән күп еллар дәвамында китапханәчеләр С.С.Гафурова, Т.И.Фомина, Г.А.Сабирова, Р.Ү.Елизарова эшли.

Татар һәм көнчыгыш әдәбияты бүлекчәсендә 3 меңгә якын борынгы кулъязма, 500 данә тарихи фотосурәт, 7 мең 500 гә якын иске басма китап, 1940



# ОТДЕЛ РУКОПИСЕЙ И РЕДКИХ КНИГ

В 1970-е годы в библиотеке был создан сектор редких и ценных книг. У истоков его создания и начала формирования фонда стояли библиотекари – Д.З.Гарифуллина, Т.А.Волонкович, Н.С.Митрофанова, Э.С.Атнагулов.

В 1992 году сектор был преобразован в отдел рукописей и редких книг с двумя секторами: татарской и восточной литературы и русской и западной литературы.

Сегодня отдел рукописей и редких книг является самостоятельным структурным подразделением библиотеки, ее специализированным научно-производственным отделом. Фонд документов отдела в настоящее время составляет около 60 тыс. единиц хранения.

Первым заведующим отдела стал ученый-археограф Р.Ф.Марданов. С 1999 года по настоящее время отдел возглавляет А.З.Загидуллин. В секторе татарской и восточной литературы начинал свою работу в библиотеке нынешний заместитель директора по научной работе И.Г.Хадиев, который курирует деятельность отдела.

В разные годы в отделе трудились старейшие работники библиотеки Н.А.Асулкаева, З.З.Валиуллина, А.Ф.Махмутова, Л.П.Юревич, Т.И.Фомина. Сегодня продолжают работу в секторе татарской и восточной литературы опытные специалисты, такие как И.Х.Ахметшина, А.Х.Гараева, Й.К.Сабитова, Г.Р.Хусайнова.

Сектор русской и западной литературы возглавляли: до 1996 года – Э.С.Атнагулов, в 1998 – 2010 годах – Г.Г.Шагиахметова, с 2015 года – Р.К.Юнусова. Вместе с ними все эти годы трудились и продолжают

нчы елларга кадәр дөнья күргән 600 данә газета, 2 мең 500 данә татар һәм көнчыгыш телләрендәге журналлар саклана. Иске басма китаплар тупланмасын гарәп графикасында 1930 елга кадәр басылган дини, әдәби, тарихи, һәм фәлсәфи эчтәлектәге китаплар тәшкил итә. Алар арасында Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдинов, К.Насыйри, Г.Исхакый, Г.Тукай, М.Җәлил һәм башка танылган татар язучылары, галимнәре, мәгърифәтчеләренең үзләре исән вакытта ук дөнья күргән басмалары бар. Бүлекчә Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең горурлыгы һәм йөзек кашы булган, XIV гасырдан алып XX гасыр башына кадәрге чорларга нисбәтле көнчыгыш кульязмалары коллекциясен саклаучы урын да булып тора. Фондта шулай ук тагын берничә уникаль коллекция тупланган: Коръән коллекциясе, Ә.Г.Кәримуллин, Р.Үтәбай-Кәрими, Ү.Байчура, Ә.Мәңгәр, Э.Р.Тенишевларның китап коллекцияләре.

Рус һәм көнбатыш әдәбияты бүлекчәсе фондында 40 мең документ саклана. Аерым коллекцияләр буларак сакланган И.А.Второв, И.А.Сахаров коллекцияләре, кульязмалар, иске басма китаплар, нәни һәм зур китаплар, репринт һәм факсимиль басмалар, милли һәм туган якны өйрәнүгә багышланган әдәбият тупланмалары аның никадәр бай һәм зур кыйммәткә ия икәнлеген күрсәтә. Россия әдипләре һәм галимнәреннән Н.Карамзин, А.Пушкин, В.Даль, М.Ломоносов, С.Соловьев һәм башкаларның үзләре исән чакта басылган әсәрләре һәм хезмәтләре дә саклана бирелә.

Бүлек сирәк, кыйммәтле һәм аерым әһәмияткә ия булган документларны эзләп табу, китапханәгә алдыру, фәнни эшкәртү һәм саклау белән шөгыльләнә, язма ядкәрләр фондына, аерым коллекцияләргә, басма китапларга һ.б. электрон рәвештә һәм карточкалы каталоглар төзи; китапханәдән файдаланучыларга хезмәт күрсәтә; моннан тыш, татар китабы тарихы өлкәсендә фәнни эзләнүләр алып бара, бүлек фондларын Татарстанда һәм республикадан читтә яшәгән милләттәшләребез арасында пропагандалый; китапханәдә һәм аннан читтә күргәзмәләр оештыра. Бүлек хезмәткәрләре тарафыннан фәнни-методик һәм наширлек эшчәнлеге дә алып барыла.

1991 елда ТР Фәннәр академиясе академигы Ә.Г. Кәримуллин (1925–2000) җитәкчелегендә башланган «Татар басма китабының җыелма каталогы (1722–1917)» төзү эше хезмәткәрләр тарафыннан дәвам иттерелә. 1992 елдан башлап, Казан федераль университеты белән берлектә, татарлар төпләнеп яшәгән регионнарга археографик экспедицияләр оештырыла.

трудиться библиотекари С.С.Гафурова, Т.И.Фомина, Г.А.Сабирова, Р.У.Елизарова.

Сектор татарской и восточной литературы насчитывает около 3000 единиц старотатарских и восточных рукописей, более 500 единиц фотоматериалов, более 7500 старопечатных книг, 600 экз. газет и 2500 экз. татарских и восточных старопечатных журналов, изданных до 1940 года.

Среди книг, хранящихся в фонде сектора, есть прижизненные издания Ш.Марджани, Р.Фахрутдинова, К.Насыри, Г.Исхаки, Г.Тукая, М.Джалиля и других известных татарских писателей, ученых и просветителей.

Сектор является хранителем коллекций редчайших восточных рукописей XIV– начала XX вв.,являющихся гордостью и жемчужиной Национальной библиотеки РТ. Фонд включает отдельные уникальные коллекции: коллекцию Корана, коллекции А.Г.Каримуллина, Р.Утябая-Карими, У.Байчуры, А.Менгера, Э.Р.Тенишева.

Сектор русской и западной литературы располагает фондом более 40 тысяч единиц хранения. Состав фонда и его многообразие раскрывается через сформированные коллекции, которые позволяют увидеть богатство и ценность собранного. В секторе выделены следующие книжные коллекции: фонд И.А.Второва, коллекция книг И.А.Сахарова, рукописное наследие, старопечатные издания, «В мире миниатюрной книги», «Наш край родной». Также хранятся прижизненные издания Н.Карамзина, А.Пушкина, В.Даля, М.Ломоносова, С.Соловьева и др.

На протяжении этих лет в своей деятельности сотрудники отдела стремились сочетать комплекс работ по сбору, хранению и научному описанию редких и особо ценных изданий с их популяризацией всеми доступными средствами, включая экскурсии по фондам, подготовку публикаций в СМИ, организацию периодически сменяемых выставок.

С целью широкого освещения истории татарской печатной книги продолжается работа по составлению фундаментального труда – «Сводного каталога татарской книги (1722-1917 гг.)», начатая в 1991 году под руководством академика Академии Наук Республики Татарстан А.Г.Каримуллина (1925–2000 годы).

С 1992 года проводятся археографические экспедиции в регионы компактного проживания татар с целью выявления и комплектования древних рукописных и печатных книжных памятников.

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ ТУГАН ЯКНЫ ӨЙРӘНҮ БҮЛЕГЕ | ОТДЕЛ ТАТАРСКОЙ И КРАЕВЕДЧЕСКОЙ ЛИТЕРАТУРЫ

Татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлеге 1971 елда ачыла. Бүлекнең төп бурычы булып татар китабын һәм Татарстан турындагы әдәбиятны туплау, саклау, өйрәнү һәм укучыларга җиткерү тора.

Бүлектә татар матур әдәбияты, тарихка һәм мәдәнияткә караган хезмәтләр, белешмә басмалар, статистика материаллары саклана. Татар телендәге, татар халкы һәм Татарстан турындагы әдәбиятның уникаль тупланмасында республикабызда гына түгел, ә аннан читтә дөнья күргән китаплар да бар.

Бүлек фондын фәннең бөтен тармакларына караган татар китаплары һәм матур әдәбият – 1928 елдан 1939 елга кадәр латин графикасында, ягъни«Яңалиф»тә, 1940 елдан хәзерге көнгә кадәр кириллицада басылган татар язучылары әсәрләре, башка теллəрдән татарчага тәрҗемә ителгән китаплар тәшкил итә.

Татарстан һәм татар халкы турында рус телендә басылган (шул исәптән 1917 елга кадәр) китаплар, татар әдипләренең русча чыккан, шулай ук Татарстанның русча язучы әдипләре иҗат иткән әсәрләр, Татарика, электрон документлар, республиканың аеруча күп сорала торган матбугат басмалары фондның шактый зур өлешен алып тора.

Бүлек фондында 146645 документ исәпләнә, шуларның 83900 берәмлеге татар телендә. Фонд ел саен яңа басмалар белән тулылана. Бүлек «Руслан» автоматлаштырылган китапханә-мәгълүмат системасында Татарстан Республикасы китапханәсенең Җыелма электрон каталогын төзүдә актив катнаша.

1934 елдан башлап төзелә торган туган якны өйрәнү системалы картотекасына китаплар, җыентыклар, Татарстан һәм Россия матбугатында татарча һәм русча басылган мәкаләләр турында мәгълүматлар тупланган; 1994 елдан әлеге картотека электрон рәвештә алып барыла.



Отдел татарской и краеведческой литературы начал функционировать в 1971 году. Основной задачей отдела является комплектование, хранение, изучение и предоставление пользователям татарской книги и литературы о Республике Татарстан.

В отделе представлены фундаментальные труды по истории и культуре, справочная литература, статистические материалы, собран уникальный фонд изданий на татарском языке и литературы о Татарстане и татарском народе, опубликованные не только в республике, но и за ее пределами.

Составными частями фонда отдела являются: книги на татарском языке по всем отраслям знаний и художественная литература – произведения татарских писателей, переводы на татарский язык с других языков, изданные в 1928 по 1939 гг. на латинской графике («Яналиф»), с 1940-х гг. до наших дней – на кириллице. Значительную часть фонда составляют издания на русском языке о Татарстане и Казанском крае (в том числе изданные до 1917 года) и художественная литература – произведения татарских писателей на русском языке, книги русских писателей Татарстана; Татарика; документы на нетрадиционных носителях, наиболее спрашиваемые республиканские периодические издания.

Фонд отдела насчитывает 146645 документов, из них 83900 единиц хранения на татарском языке, который ежегодно пополняется новыми поступлениями. Отдел активно участвует в создании Сводного электронного библиотечного каталога Республики Татарстан в автоматизированной библиотечно-информационной системе «РУСЛАН».

В «Систематической картотеке о Республике Татарстан», организованной в 1934 году, содержится аналитическая информация из книг, сборников, российской и республиканской периодической печати




Бүлек файдаланучыларга хезмәт күрсәтү, белешмә-библиография эше, фонд белән эшләү секторларына бүленгән.

Бүлек эшчәнлегенең төп юнәлеше түбәндәгеләр:

– бүлек фондын туплау, исәпкә алу, саклау;

– бүлекнең электрон һәм традицион каталогларын һәм картотекаларын оештыру, алып бару һәм редакцияләү;

– бүлекнең уку залында документларны вакытлыча файдалануга бирү;

– белешмә-библиография хезмәте: һәр типтагы һәм төрдәге белешмәләр бирү; библиографик чыганаклардан һәм мәгълүматлар базаларыннан файдалану буенча консультация бирү;

– мәгълүмат хезмәте күрсәтү: бүлектә һәм китапханәдән читтә тематик һәм аерым шәхесләргә багышланган күргәзмәләр оештыру; Мәгълүмат һәм белгеч көннәре үткәрү; китапларга библиографик күзәтүләр ясау һәм консультация бирү; китапханәнең Web-сайтына мәгълүматлар урнаштыру;

– белешмә-библиографик һәм мәгълүмати кулланмалар, ярдәмлекләр әзерләп чыгару: «Татарстан Республикасының истәлекле һәм онытылмас даталар календаре»н нәшер итү (һәр ел саен); туган якны өйрәнү буенча татар һәм рус телләрендә библиографик күрсәткечләр төзү; бүлек юнәлеше буенча әдәби-библиографик исемлекләр, белешмәлекләр, актуаль темаларга караган буклетлар төзү;

– бүлек юнәлеше буенча фәнни-тикшеренү һәм фәнни-методик эшчәнлек алып бару;

– алдынгы технологияләрне, мәгълүмат чыганакларын һәм хезмәт күрсәтүнең яңа формаларын гамәлгә кертү.

Татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлегендә 14 хезмәткәр эшли. Барлык хезмәткәрләр югары белемле, 7-се махсус китапханә белеме алган; күбесенең китапханәдә эшләү стажы 20 елдан артык. Алар югары профессиональ дәрәҗәле, китапханә эшен белүче, үз һөнәрләрен яратучы белгечләр.

на татарском и русском языках; с 1994 года ведется электронная версия картотеки.

В структуру отдела входят: сектор обслуживания пользователей, сектор справочно-библиографической работы, сектор работы с фондами.

Основными направлениями деятельности отдела являются:

– организация, учет, хранение и обеспечение сохранности фондов отдела;

– организация, ведение и редакция электронных и традиционных каталогов и картотек отдела;

– предоставление документов во временное пользование в читальном зале отдела и через абонемент художественной литературы;

– справочно-библиографическое обслуживание: выполнение справок всех типов и видов; консультации по поиску и использованию библиографических источников и БД;

– информационное обслуживание: организация книжных выставок; дней информации и специалиста; проведение библиографических обзоров документов и консультаций; размещение информации на Web-сайте библиотеки;

– создание библиографических продуктов: «Ка-



лендаря знаменательных и памятных дат Татарстана» (ежегодно); краеведческих указателей литературы на татарском и русском языках; библиографических списков литературы, справочников, буклетов по актуальным темам по профилю отдела;

– научно-исследовательская и научно-методическая работа по профилю отдела;

– внедрение инновационных технологий и форм обслуживания.

В отделе татарской и краеведческой литературы работают четырнадцать человек. Все сотрудники с высшим образованием, из них семь человек имеют высшее профессиональное образование; стаж работы многих в библиотеке составляет более двадцати лет. Коллектив отдела – это содружество единомышленников и профессионалов высокого класса.

# МӘГЪЛҮМАТ-БИБЛИОГРАФИЯ БҮЛЕГЕ

# ИНФОРМАЦИОННО-БИБЛИОГРАФИЧЕСКИЙ ОТДЕЛ

Чиксез мәгълүматлар галәмендә үзеңә кирәклесен табу осталыгы һәркемгә дә бирелмәгән. Һөнәри белем, эш тәҗрибәсе һәм, мөгаен, билгеле бер библиографик сиземләү бу эштә ярдәм итә. Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең мәгълүмат-библиография бүлеге коллективы шушы сыйфатларга ия. 80 елдан артык бүлек хезмәткәрләре мәгълүмат һәм аннан файдаланучылар өчен арадашчы ролен уңышлы башкаралар.



Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең иң өлкән әлеге бүлеге 1934 елда оештырыла. Бүлек фондында 65 000 нән артык документ саклана. Биредә белешмә һәм энциклопедик басмаларның төрле белем тармакларына караганнары, биографик сүзлекләр, рус теле сүзлекләре, статистик җыентыклар, шәһәрләр һәм илләр буенча юлкүрсәткечләр, библиографик басмалар, реферАтив журналлар һ.б. басмалар саклана. Хәзерге көндә әлеге мәгълүмати тупламга электрон ресурслар да килеп өстәлде: интернет, электрон каталоглар, дисклардагы басмалар, белешмә-хокукый системалар.

**Мәгълүмат-библиография бүлеге эшчәнлегенең төп юнәлешләре:**

– универсаль белешмә-библиографик фонд, библиографик һәм реферАтив вакытлы матбугат, электрон ресурслар һәм традицион белешмә-библиографик аппарат нигезендә файдаланучыларга һәм оешмаларга белешмә-библиографик һәм мәгълүмат хезмәте күрсәтү;

– бүлек фондында электрон каталог, мәкаләләрнең электрон картотекасын булдыру, фәнни-ярдәмчел һәм тәкъдим рәвешендәге, туган якка багышланган, традицион һәм электрон рәвештәге библиографик басмалар төзү;

– Татарстан Республикасы Милли китапханәсе сайтын (http:// kitaphane. tatarstan.ru) һәм «Татарстан

Найти необходимую информацию в огромном информационном пространстве – искусство, доступное не всем. Следует обладать профессиональными знаниями, опытом работы и, наверное, определенным – библиографическим – чутьем. Все это сложилось в коллективе информационно-библиографического отдела Национальной библиотеки Республики Татарстан в нужных пропорциях. Вот уже более 80 лет сотрудники информационно-библиографического отдела успешно выступают в роли посредников между информацией и пользователем.

Информационно-библиографический отдел – один из старейших отделов Национальной библиотеки РеспубликиТатарстан, он был организован в 1934 году. Фонд отдела насчитывает более 65 тысяч документов. Это справочные и энциклопедические издания всех типов и по всем отраслям знаний, биографические словари, словари русского языка, статистические сборники, путеводители по городам и странам, библиографические издания, реферативные журналы и пр. В настоящее время к этому массиву информации добавились электронные ресурсы: Интернет, электронные каталоги, издания на дисках, справочно-правовые системы.

**Основные направления деятельности отдела:**

– справочно-библиографическое и информационное обслуживание пользователей и организаций на основе универсального справочно-библиографического фонда, библиографической и реферативной периодики, электронных ресурсов и традиционного справочно-библиографического аппарата;

– создание электронного каталога на фонд отдела, электронной картотеки статей, научно-вспомогательных и рекомендательных краеведческих библиографических изданий в традиционной и электронной форме;

Республикасы Милли электрон китапханәсе» порталын (http://kitap.tatar.ru) мәгълүмат белән тулыландыруда ярдәм күрсәтү;

– махсуслаштырылган мәгълүмат көннәре, библиографик семинарлар, библиография мәсьәләләре буенча күзәтүләр, шәхси һәм төркемләп оештырылган консультацияләр үткәрү юлы белән файдаланучыларның мәгълүмати культурасын формалаштыруда катнашу;

– файдаланучыларның хокукый белемен арттыруда мәгърифәт эшчәнлеген оештыру;

– республика китапханәләрендәге мәгълүматбиблиография эшен фәнни-методик яктан тәэмин итү.

Бүлекнең төзелеше:

**Хокукый мәгълүматларның республика үзәге**

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең хокукый мәгълүматлар үзәге 1999 елның 4 июнендә Россия Федерациясе хөкүмәт элемтәсе үзәге катнашында ачылды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2004 елның 9 июлендә кабул иткән (№981-р) карар нигезендә ул Республика хокукый мәгълүматлар җәмәгать үзәге (РХМҖҮ)дип үзгәртелде. Әлеге үзәк хокукый мәгълүмат эзләүчеләргә квалификацияле ярдәм күрсәтә, Татарстан Республикасы үзәкләштерелгән китапханәләр системаларының хокукый үзәкләре белән методик җитәкчелек итә.

**Мәдәният һәм сәнгать мәгълүматлары үзәге**

Мәдәният һәм сәнгать мәгълүматлары үзәге Россия Федерациясенең «Мәдәният турында РФ законнары нигезләре» Законының 37 һәм 39 нчы маддәләренә, Росинформкультура турындагы Нигезләмәгә, Россия дәүләт китапханәсенең мәдәният һәм сәнгать фәнни-тикшеренү үзәге методик җитәкчелеге күрсәтмәләренә таянып эшли.

**Аның төп эш юнәлешләре:**

– мәдәният һәм сәнгать мәсьәләләре белән шөгыльләнүче дәүләт структуралары эшчәнлеген мәгълүмат белән тәэмин итү;

– мәдәниятне әйдәп баручы хезмәткәрләргә мәгълүмати ярдәм күрсәтү;

– ерактагы файдаланучыларга мәгълүмати ярдәм күрсәтү (мәдәният һәм сәнгать мәгълүматлары үзәге сайты http://kitaphane.tatarstan.ru/rus/ciki.htm)

– мәдәният һәм сәнгатькә караган мәгълүмат ресурсларын ачыклау һәм өйрәнү;

– мәдәният һәм сәнгать мәгълүматларын туплаган электрон ресурслар төзү.

**Бүлекнең белешмә-библиографик аппараты:**

– мәкаләләрнең электрон картотекасы (1994 елдан башлап);

– электрон каталог;

– информационная поддержка сайта Национальной библиотеки Республики Татарстан (http://kitaphane.tatarstan.ru) и портала «Национальная электронная библиотека Республики Татарстан» (http://kitap.tatar.ru);

– участие в формировании информационной культуры пользователей путем проведения индивидуальных и групповых консультаций, специализированных Дней информации, библиографических семинаров, обзоров по вопросам библиографии;

– организация просветительской деятельности в области правовой грамотности пользователей;

– научно-методическое обеспечение информационно-библиографической работы библиотек республики.

В структуре отдела:

**Республиканский центр правовой информации**

Центр правовой информации Национальной библиотеки Республики Татарстан был открыт 4 июня 1999 года при участии Центра правительственной связи Российской Федерации в Республике Татарстан. Согласно Распоряжению Кабинета Министров РТ от 9 июля 2004 г. №981-р, он преобразован в Республиканский публичный центр правовой информации (РПЦПИ). Центр оказывает квалифицированную помощь в поиске правовой информации, обучает навыкам работы с предоставляемыми базами данных, осуществляет методическое руководство правовыми центрами централизованных библиотечных систем Республики Татарстан.

**Центр информации по культуре и искусству**

Центр действует на основании статей 37 и 39 Закона Российской Федерации «Основы законодательства РФ о культуре», Положения о Росинформкультуре. Методическое руководство им осуществляет НИЦ Информкультура (Научно-исследовательский центр по культуре и искусству Российской государственной библиотеки).

**Основные направления работы центра:**

– информационное обеспечение деятельности государственных структур, занимающихся вопросами культуры и искусства;

– информационное обслуживание ведущих работников культуры;

– информационное обслуживание удаленных пользователей (сайт Центра информации по культуре и искусству – http://kitaphane.tatarstan.ru/rus/ciki.htm);

– выявление и изучение информационных ресурсов по культуре и искусству;

– создание электронных ресурсов по культуре и искусству.



– бүлектәге журналларның электрон каталогы;

– тулытекстлы хокукый белешмәләр базалары: «Консультант Плюс» белешмә-хокукый системасы, «Гарант» белешмә-хокукый системасы, «Россия законнары» дигән мәгълүмат-хокукый системасы;

– «Информкультура» фәнни-тикшерену үзәгенең белешмәләр базасы;

– «ВИНИТИ реферативжурналлары»ның белешмәләр базасы (2011 елдан алып);

– Тематик белешмәләр базасы.

**Бүлекнең хезмәт күрсәтү төрләре:**

– белешмә-библиография хезмәте күрсәтү:

– китапханә фонды составы турында мәгълүмат бирү;

– белешмә-мәгълүмат чыганакларында эзләнүгә ярдәм итү;

– барлык төрдәге белешмәләрне үтәү.

**Мәгълүмат хезмәте күрсәтү:**

– оешмаларга беренчел мәгълүмат хезмәте күрсәтү;

– «Мәгълүмат көннәре» һәм «Белгеч көннәре» үткәрү;

– традицион һәм электрон рәвештә библиографик басмалар, исемлекләр, дайджестлар, күрсәткечләр, белешмәлекләр төзү;

– белешмәләр базасында һәм Интернет челтәрендә эзләнү.

**Документлар хезмәте күрсәтү:**

– бүлек фондыннан документларны вакытлыча файдаланырга биреп тору;

– документларның ксерокүчермәләрен ясау һәм принтерда бастыру.

Гомер уза, технологик процесслар үзгәрә, мәгълүматның яңа чыганаклары барлыкка килә, ләкин библиографларның девизы гына үзгәрми: кулланучыга мәгълүматны үз вакытында һәм тулы күләмдә бирергә. Без шуның өчен эшлибез!

**Справочно-библиографический аппарат отдела:**

– электронная картотека статей (с 1994 года);

– электронный каталог;

– электронный каталог журналов отдела;

– полнотекстовые правовые базы данных: справочно-правовая система «Консультант Плюс», справочная правовая система «Гарант», информационно-правовая система «Законодательство России»;

– база данных НИЦ «Информкультура»;

– база данных «Реферативные журналы ВИНИТИ» (с 2011 года);

– тематическая база данных.

**Услуги:**

Справочно-библиографическое обслуживание:

– предоставление информации о составе библиотечного фонда;

– консультации по поиску в справочно-информационных источниках;

– выполнение справок всех типов и видов.

**Информационное обслуживание:**

– приоритетное информационное обслуживание учреждений;

– проведение Дней информации и Дней специалиста;

– создание библиографических изданий: списков, дайджестов, указателей, справочников в традиционной и электронной форме;

– поиск в базах данных и сети Интернет.

**Документное обслуживание:**

– выдача документов из фондов отдела во временное пользование;

– ксерокопирование документов и распечатка из баз данных.

Идут года, меняются технологические процессы и операции, появляются новые носители и источники информации, но девиз библиографов остается прежним – дать человеку нужную информацию в полном объеме и вовремя. Над этим мы трудимся каждый день!



# ДОКУМЕНТЛАР ТУПЛАУ БҮЛЕГЕ

һәр китапханәнең нигезен аның фонды тәшкил итә. Татарстан Милли китапханәсе дә Республиканың гаять кыйммәтле хәзинәсен саклаучы мәдәни объект булып санала. Аның уникальлеге – фондларның тулылыгында һәм универсаль булуында. Документлар туплау бүлеге китапханә оештырылган көннән алып түбәндәге эшләрне башкара:

– милли һәм туган якны өйрәнүгә караган документларны тулысынча туплый һәм мәңге саклый;

– фондны илебездә нәшер ителгән күптөрле әсәр-хезмәтләр һәм фәнни әһәмияте зур булган документлар белән тулыландыра;

– Идел һәм Урал буенда яшәүче халыклар телләрендәге документларны туплый;

– Республиканың иң эре китапханәләре белән фондлар туплау һәм тулыландыру юнәлешендә үзара килешеп эшли.

Китапханә фондын туплауның чыганаклары:

– Республика җирлегендә дөнья күрүче басмаларның мәҗбүри нөсхәсе;

– Россия һәм Татарстан нәшриятлары һәм нәшер итүче оешмалары, республикадагы югары уку йортлары нәшриятлары;

– Россия һәм Татарстанның китап сәүдәсе ширкәтләре һәм китап кибетләре;

– Халыкара һәм төбәкара китап алмашу;

– Россия, Татарстанда һәм чит илләрдә даими чыгучы басмаларга (вакытлы матбугатка) язылу;

– Шәхси ширкәтләр һәм шәхесләр, китап авторлары;

– Китап укучылар, авторлар һәм оешмалар бүләк иткән китаплар.

«Китапханәләр һәм китапханәләр эше турында» (1998) һәм «Документларның мәҗбүри нөсхәсе

# ОТДЕЛ КОМПЛЕКТОВАНИЯ ДОКУМЕНТОВ

Основу всех библиотек составляют их фонды. Национальная библиотека Республики Татарстан относится к особо ценным объектам культуры республики. Ее уникальность – в полноте и универсальности фондов. Отдел комплектования документов с момента создания библиотеки и организации отдела как отдельного структурного подразделения занимается:

– формированием фонда национально-краеведческих документов по принципу исчерпывающей полноты и вечности хранения;



– наиболее полным комплектованием фонда отечественными собраниями и научно-значимыми зарубежными документами;

– комплектованием фонда документами на языках народов Поволжья и Приуралья.

– координацией вопросов комплектования фондов с крупнейшими библиотеками республики.

Источниками комплектования библиотеки являются:

– Республиканский обязательный экземпляр;

– Издательства и издающие организации России и Татарстана, издательства вузов республики;

– Книготорговые фирмы, книжные магазины России и Татарстана;

– Международный и межрегиональный книгообмен;

– Подписка на периодические издания России, Татарстана и зарубежных стран;

– Частные фирмы и лица, авторы книг;

– Дары от читателей, авторов и организаций.

В соответствии с Законом РТ «О библиотеках и библиотечном деле» (1998г.) и Законом РТ «Об обязательном экземпляре документов» (2005г.), в библиотеку поступает свыше 3500 экз. книжной продукции, более 400 названий газет и журналов, выходящих на

турында»гы (2005) Татарстан Республикасы законнары нигезендә бер ел дәвамында китапханәгә Татарстанда чыгучы 3500 данәдән артык китап продукциясе, 400 исемнән артык газета һәм журналлар килә. Ел саен фонд 18000 нән артык документ белән тулылана. Бүләк рәвешендә оешмалардан кергән 3000 ләп документ, шәхси затлардан алынган 2000 ләп документ хисабына да фонд күпкә байый. Бүлек Республиканың үзәкләштерелгән китапханәләр системалары фондларын, халыкара һәм төбәкара китап алмашу бүлеге фондын тулыландыру белән дә шөгыльләнә. Хәзерге көндә ул Россия һәм Татарстанның иң эре нәшриятлары белән турыдантуры, ягъни арадашчылар ярдәменнән башка эшли, шуңа күрә файдаланучыларның үтенече бик тиз канәгатьләндерелә.

Китапханәнең документлар туплау бүлеге «Татарика» фондын оештыруга да үз өлешләрен кертә, ягъни республикадан читтә басылган, татар халкына, аның яшәеше, тарихы, мәдәнияте һәм сәнгатенә багышланган агымдагы һәм ретроспектив документлар башта биредә җыела.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе – Россиядә һәм Татарстанда чыгып килүче вакытлы матбугат басмаларының аеруча тулы тупланмаларын алдыручы бердәнбер китапханә. Бу юнәлешнең республикакүләм координаторы буларак, бүлек ел саен «Казан шәһәренең иң эре китапханәләре тарафыннан яздырып алына торган җыелма каталог»ын әзерли.

Китапханәгә килүче барлык документларны теркәүне бүлек «Руслан» автоматлаштырылган китапханә-мәгълүмат системасы ярдәмендә башкара. Китапханә оештырылган көннән алып бүгенгәчә тутырылган барлык инвентарь кенәгәләре дә шушы бүлектә саклана. Биредә республика үзәкләштерелгән китапханәләр системаларына фәнни-методик ярдәм дә күрсәтәләр, фондны туплау һәм оештыруга караган сораулар белән мөрәҗәгать иткән башка система һәм ведомство китапханәләренә дә булышлык итәләр.

Документлар туплау бүлегендә 7 хезмәткәр эшли. Барлык белгечләр дә югары белемле, шулар арасыннан 5-се югары китапханә белеменә ия.

территории Татарстана. Ежегодно в фонд поступает около 18 000 документов. В дар от организаций – 3000 документов, от частных лиц – 2000 документов. Отдел занимается пополнением фондов централизованных библиотечных систем республики и фонда отдела международного и межрегионального книгообмена. Сегодня отдел напрямую работает с крупнейшими издательствами России и Татарстана, удовлетворяет спрос пользователя в кратчайшие сроки.

Одной из задач библиотеки является формирование фонда «Татарика». Отдел комплектования документов занимается текущим и ретроспективным комплектованием документов о татарском народе, его истории и культуре, выходящих за пределами республики.

Национальная библиотека Республики Татарстан является единственной библиотекой в регионе, получающей наиболее полный комплект периодических изданий, выходящих в России и Татарстане. Отдел координирует вопросы подписки на периодические издания и ежегодно готовит «Сводный каталог, периодических изданий, выписываемых крупнейшими библиотеками г. Казани».

Отделом осуществляется учет всех поступающих в библиотеку документов в автоматизированной бибиотечно-информационной системе «Руслан». С момента создания библиотеки инвентарные книги всех видов хранятся в отделе. Здесь оказывают научно-методическую помощь всем Централизованным библиотечным системам республики, дают консультации и рекомендации библиотекам других систем и ведомств по вопросам комплектования и формирования фондов.

В отделе комплектования документов работают 7 сотрудников. Все специалисты с высшим образованием, 5 из них имеют высшее библиотечное образование.



# РЕСПУБЛИКАДАГЫ КИТАПХАНӘЛӘРГӘ КИТАП ТУПЛАУ БҮЛЕКЧӘСЕ

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе китап туплау бүлегенең республикадагы китапханәләргә китап туплау бүлекчәсе 1994 елда оештырыла. Бүген бүлекчә бибколлектор, ягъни муниципаль китапханәләргә китап җибәрүче вазыйфасын үти дияргә мөмкин. Ул Татарстан Республикасы мәдәният министрлыгы системасындагы китапханәләрне Татарстан китап нәшрияты чыгарган басмалар, Татарстандагы башка нәшриятларның татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнүгә караган китаплары, шулай ук чуваш, мордва, мари, удмурт, башкорт әдәбияты белән тәэмин итә.



Бүлекчә штатында 5 кеше. Оешу көненнән үк аны Сафина Луиза Зөфәр кызы җитәкли, 15 ел дәвамында Хәйруллина Галия Харис кызы, 10 елга якын Исламова Илсөяр Каюм кызы эшли, 2010 ел ахырында коллективка Чепик Наталия Геннадьевна кушылды.

Татарстан Министрлар Кабинеты республиканың муниципаль һәм республика (дәүләт) китапханәләренә татар китаплары һәм туган якны өйрәнүгә караган әдәбият туплау өчен ел саен бүлеп бирә торган акчаны тиешле максатта тоту эшләрен менә инде 20 ел дәвамында нигездә Милли китапханә башкара.

Бүлекчә эшендәге мөһим юнәлешләрнең берсе – Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республкасы Дәүләт программасын гамәлгә ашыру. 2014 ел дәвамында гына да 19,7 млн. сумлык 50 мең данә басма шушы программа кысаларында муниципаль китапханәләргә таратылды. Соңгы берничә ел эчендә шактый күп сандагы китап «Татарстан Республикасында яшьләргә патриотик тәрбия

# СЕКТОР КОМПЛЕКТОВАНИЯ БИБЛИОТЕК РЕСПУБЛИКИ

Сектор комплектования библиотек республики отдела комплектования Национальной библиотеки Республики Татарстан создан в 1994 году. Можно сказать, что сектор сегодня выполняет функции бибколлектора – основного поставщика литературы для муниципальных библиотек. Он комплектует библиотеки системы Министерства культуры Республики Татарстан изданиями, выпускаемыми Татарским книжным издательством, татарской и краеведческой литературой, выпускаемой другими издательствами Республики Татарстан, а также чувашской, мордовской, марийской, удмуртской, башкирской литературой.

В штате сектора 5 человек. С момента создания его возглавляет Сафина Луиза Зуфаровна, 15 лет работает Хайруллина Галия Харисовна, около 10 лет трудится Исламова Илсояр Каюмовна, в конце 2010 года пришла в коллектив Чепик Наталия Геннадьевна.

Национальная библиотека в течение 20 лет является основным исполнителем мероприятий по освоению ежегодно выделяемых Кабинетом Министров Республики Татарстан средств на комплектование муниципальных и республиканских (государственных) библиотек Республики Татарстан татарской и краеведческой литературой.

Важным направлением работы сектора комплектования является работа по реализации Государственной программы Республики Татарстан по сохранению, изучению и развитию языков народов Республики Татарстан. Только за 2014 год в рамках программы муниципальным библиотекам было передано около 50 тысяч экземпляров изданий на общую сумму 19,7 млн.рублей. На протяжении

бирү» дип аталган, 2011–2013 елларга исәпләнгән максатчан программа нигезендә сатып алынды һәм республикадагы китапханәләргә тапшырылды. 2011–2015 елларга төзелгән, Татарстан Республикасында халыкны наркотиклардан кисәтү максатчан программасын үтәү буенча да эшләр башкарыла. Ел саен китап туплау бүлекчәсе республиканың муниципаль китапханәләрен Татарстан бюджетыннан бүлеп бирелгән акча хисабына республика газета һәм журналларына яздыруны оештыра.

Татарстан китап нәшрияты чыгара торган социаль әһәмиятле әдәбиятның күп өлешен 2011 елдан башлап Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең республикадагы китапханәләргә китап туплау бүлекчәсе тарата. Муниципаль китапханәләр фондларының тотрыклы үсеше нәкъ менә социаль әһәмиятле әдәбият нәшер итү нигезендә барлыкка килде. 2011 елдан республикадагы муниципаль китапханәләрнең гомуми фонды 200 мең данәгә диярлек артты. Социаль әһәмиятле әдәбият исемлегендә хәзерге заман татар шигърияте һәм проза әсәрләре, татар әдәбияты классикларының тәрҗемә китаплары, балалар һәм яшүсмерләр басмалары, тарихка, иҗтимагый фикер темасына, Татарстанның һәм Казанның үткәненә багышланган хезмәтләр бар. Алар укучылар тарафыннан еш сорала.

«Рухият» рухи яңарыш фонды, республика театрлары һәм вакытлы матбугат редакцияләре, төрле оешмалар һәм аерым затлар үзләре тарафыннан чыгарылган басмаларны республиканың муниципаль китапханәләренә тапшыруны сорап мөрәҗәгать итәләр. Шушы рәвешчә китерелгән басмалар китапханәләргә бушлай өләшенә.

Йомгаклап әйткәндә, бүлекчә муниципаль китапханәләр фондларына китап туплау, китап продукциясен бүлү һәм тапшыру, китапханәләргә аеруча кирәкле басмаларның күләмен һәм сыйфатын ачыклауга корылган сораштырулар үткәрү, китапханә фондларын исәпкә алу мәсьәләләрендә методик ярдәм күрсәтү, китапханәләр фондларына китап туплауның төрле үзенчәлекләрен анализлау эшләрен башкара. Әгәр республикабызның ерак авыл китапханәсендә укучы кулларына яңа китап ала яки көндәлек матбугат укый икән, монда безнең хезмәтнең дә өлеше бар.

ряда лет значительное количество изданий было приобретено и передано в библиотеки республики в рамках реализации целевой программы «Патриотическое воспитание молодежи Республики Татарстан на 2011– 2013 годы». Ведется работа в рамках целевой долгосрочной программы профилактики наркотизации населения в Республике Татарстан на 2011– 2015 годы. Ежегодно сектор комплектования распределяет между муниципальными библиотеками республики подписку на республиканские газеты и журналы, средства на которую выделяются из бюджета Республики Татарстан.

С 2011 года сектор комплектования Национальной библиотеки РТ распределяет большую часть тиража социально значимой литературы, издаваемой ГУП РТ «Татарское книжное издательство». Именно изданию социально значимой литературы муниципальные библиотеки обязаны стабильным ростом библиотечных фондов. С 2011 года совокупный библиотечный фонд муниципальных библиотек республики увеличился почти на 200 тысяч экземпляров. Социально значимая литература в фондах библиотек представлена изданиями современной татарской поэзии и прозы, переводными произведениями классиков татарской литературы, детской и юношеской литературой, сочинениями по истории Татарстана и др. Книги на русском и татарском языках заслуженно пользуются спросом у читателей.

Фонд духовного возрождения «Рухият», республиканские театры и редакции журналов, различные организации и частные лица также обращаются в Национальную библиотеку РТ, в сектор комплектования с просьбой о передаче их изданий в муниципальные библиотеки республики. Все поступающие издания безвозмездно передаются в муниципальные библиотеки республики.

Таким образом, сектор комплектования ведет работу по комплектованию библиотечных фондов муниципальных библиотек, по распределению и передаче книжной продукции, проводит опросы по количеству и качеству необходимых библиотекам изданий, оказывает методическую помощь в вопросах учета библиотечных фондов, проводит анализ по различным аспектам комплектования библиотечных фондов муниципальных библиотек. Когда в отдаленной сельской библиотеке нашей республики читатель открывает новую книгу или читает свежую республиканскую прессу, в этом есть частичка и нашего труда.

# ФӘННИ-МЕТОДИК БҮЛЕК | НАУЧНО-МЕТОДИЧЕСКИЙ ОТДЕЛ

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе республикабыз территориясендә урнашкан барлык дәүләт, оешма һәм ведомство китапханәләренең эшен координацияләүче эре фәнни-методик үзәк булып тора. Әлеге хезмәтне төп башкаручы фәнни-методик бүлек республика дәрәҗәсендәге һәм муниципаль китапханәләр белән тыгыз һөнәри элемтәдә тора һәм китапханәләр эшенә яңадан-яңа формалар һәм алымнар кертүдә зур эш башкара.



Бүлекнең тарихына күз салсак, 1936 елда ул Мөхетдинова Рәйсә Зариф кызы һәм Хәбибуллина Зәйнәп Шакир кызы тарафыннан методик кабинет буларак ачыла, ә инде 1938 елда методик бүлек итеп үзгәртелә. Шул вакыттан алып республика китапханәчеләре арасында китапханә белемен тарату һәм аңлату буенча бүлек тарафыннан планлы эш алып барыла. Бөек Ватан сугышы елларында хәлләр авырая төшә. Сугыштан соңгы елларда Ж.С.Фәттахова, М.С.Иванова, О.Г.Старцева, М.Х.Делешова, Р.И. Файбусович кебек үз эшен яхшы белгән хезмәткәрләр эшкә килү белән бүлекнең эшчәнлеге җайланып китә. Китапханәчеләрнең һөнәри осталыгын арттыру, эштә яңа алымнар куллану, республика китапханәчеләре белән тәҗрибә алмашу даими рәвештә алып барыла. 1976–1980 елларда Татарстанда бөтен китапханәләр системасын үзәкләштерү башлана. Әлеге әһәмиятле һәм

Национальная библиотека Республики Татарстан является крупным научно-методическим центром, координирующим деятельность библиотек всех систем и ведомств, расположенных на территории республики. Возглавляет эту работу научно-методический отдел путём внедрения новых форм и методов в практику библиотек, профессионального взаимодействия с республиканскими и муниципальными библиотеками.

История отдела, у истоков которого стояли Мухитдинова Раиса Зарифовна и Хабибуллина Зайнап Шакировна, начинается в 1936 году с открытия методического кабинета, преобразованного в 1938 году в методический отдел. С этого времени ведётся планомерная деятельность по распространению библиотечных знаний среди библиотекарей республики. В годы войны работа методического отдела затрудняется. Активизация деятельности отдела происходит в послевоенные годы с приходом нового состава сотрудников: Ж.С.Фаттаховой, М.С.Ивановой, О.Г.Старцевой, М.Х.Делешовой, Р.И.Файбусович. Становится регулярной работа по повышению профессиональной квалификации библиотекарей с применением новых методов обучения, происходит обмен опытом между библиотеками республики. В 1976–1980 годах осуществляется централизация всей библиотечной системы Татарстана. Эту важную и сложную работу провели специалисты научно-методического отдела Р.У.Измайлова, Н.А.Асулкаева, Е.Г.Логинова (Шемелова) и др. совместно с министерством культуры ТАССР. Для многих сотрудников библиотеки работа в научно-методическом отделе стала отправной точкой карьерного роста.

Сегодня здесь работают опытные специалисты, профессионалы своего дела. С 2013 года возглавляет отдел Давлетшина Светлана Римовна. В 1985 году начали трудовую деятельность Зуева Ольга Ивановна, заведующая сектором инновационной работы библиотек и Хусаинова Эльвира Гусмановна, главный библиотекарь и социолог. С 1994 года в отделе работают главные библиотекари Замалиева Зайнаб



катлаулы эшне бүлек хезмәткәрләре Р.У.Измайлова, Н.Ә. Асылкаева, Е.Г.Логинова (Шемелова) һәм башкалар ТАССР мәдәният министрлыгы белән берлектә башкаралар. Фәнни-методик бүлектә эшләүчеләрнең күбесенең хезмәт баскычыннан югары күтәрелүе биредә башлана.

Хәзерге көндә бүлектә тәҗрибәле белгечләр, үз эшенең осталары эшли. 2013 елдан бүлекне Дәүләтшина Светлана Рим кызы җитәкли. 1985 елда китапханәләрнең яңача эшләве секторы мөдире Зуева Ольга Ивановна, баш китапханәче һәм социолог Хөсәенова Эльвира Госман кызы биредә хезмәт юлын башлыйлар. Баш китапханәчеләр Җамалиева Зәйнәп Әбугали кызы һәм Фәтхиева Кира Бексовна 1994 елда, ә Гаязова Рәмзия Ринат кызы бүлеккә 1999 елда эшкә киләләр. 2015 елда бүлеккә яңа килгән хезмәткәр Шиһабетдинова Рәсимә Ринат кызы да һөнәренең серләрен тырышып өйрәнә.

2015 елның 1 гыйнвары мәгълүматларына караганда Татарстан халкына Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына караган 1545 китапханә (Татарстан Республикасы Милли китапханәсе, Республика яшүсмерләр китапханәсе, Республика балалар китапханәсе, Күрмәүчеләр һәм начар күрүчеләр өчен Республика махсус китапханәсе һәм 1541 муниципаль китапханә) хезмәт күрсәтә.

Республика китапханәләре эшчәнлегенең барлык мәсьәләләре Татарстан Республикасы мәдәният министрлыгы белән берлектә хәл ителә. Фәнни-методик бүлеккә республика районнарындагы китапханәләрнең хәлен, алар эшендәге кыенлыкларны ачыклау, аларны бетерү юлларын күрсәтү,

Абугалиевна и Фатхеева Кира Бексовна, а с 1999 года – Гаязова Рамзия Ринатовна. В связи с укрупнением отдела в 2015 году принята на работу Шигабутдинова Расима Ринатовна.

На первое января 2015 года библиотечное обслуживание населения Татарстана осуществляют 1545 общедоступных библиотек системы министерства культуры РТ. В их числе 4 республиканские библиотеки (Национальная библиотека РТ, Республиканская юношеская библиотека, Республиканская детская библиотека, Республиканская специальная библиотека для слепых и слабовидящих) и 1541 муниципальная библиотека.

Все вопросы библиотечной деятельности республики решаются Национальной библиотекой РТ в тесном сотрудничестве с Министерством культуры РТ. При этом важнейшими направлениями работы научно-методического отдела являются мониторинг состояния библиотечного дела в районах республики, прогнозирование деятельности государственных и муниципальных библиотек; определение основных направлений научно-методической и научно-исследовательской деятельности в государственных и центральных муниципальных библиотеках; координация научно-методической деятельности государственных и муниципальных библиотек и др.

Научно-методический отдел библиотеки готовит ежегодные аналитические сборники «Государственные и муниципальные библиотеки Республики Татарстан». Для этого составляется Основной Свод годовых сведений об общедоступных (публичных) библиотеках системы Министерства культуры РТ с использованием информационно-аналитической системы БАРС. Web-Своды – программный комплекс, который ускоряет обработку информации о библиотечной деятельности в регионе на основе web-технологии в online-режиме через Интернет. Комплекс используется научно-методическим отделом Национальной библиотеки РТ, республиканскими и муниципальными библиотеками РТ с 2010 года.

Новые технологии формируют новое информационное пространство, которое влияет на формы общения библиотеки и читателя. Активно развиваются проекты по созданию электронных каталогов (в том числе сводного) с подключением к нему республиканских и муниципальных библиотек Татарстана.

Специалисты научно-методического отдела Национальной библиотеки РТ оказывают систематическую методическую и консультационную помощь муниципальным библиотекам республики и библиотекам

дәүләт һәм муниципаль китапханәләр эшен фаразлау, дәүләт һәм үзәк муниципаль китапханәләрнең фәнни-методик һәм фәнни-тикшерү эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгеләү, дәүләт һәм муниципаль китапханәләрнең фәнни-методик эшен координацияләү эше дә йөкләнгән.

Китапханәнең фәнни-методик бүлеге ел саен «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль китапханәләре» дигән аналитик җыентык чыгара. Әлеге хезмәт мәдәният министрлыгы системасына караган китапханәләрнең еллык эш мәгълүматлары нигезендә, БАРС мәгълүмати-аналитик системасын кулланып башкарыла.

Бүлек эшендә яңалыклар берсе артыннан икенчесе туып кына тора. Электрон каталоглар (шул исәптән җыелма каталогны) төзү һәм аңа Татарстанның барлык китапханәләрен тоташтыру проекты гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең фәнни-методик бүлеге хезмәткәрләре республика муниципаль китапханәләренә һәм башка ведомостволарга караган китапханәләргә дә даими рәвештә методик һәм консультация ярдәме күрсәтәләр. Китапханә эшен оештыруның төрле мәсьәләләре, шул исәптән хисап бирү формалары, китап фондларын оештыру, методик эшләрне алып баруга караган күп кенә файдалы киңәшләр бирелә.

Методик ярдәмнең иң әһәмиятлесе – методик кулланма-ярдәмлекләр төзү һәм бастырып чыгару. Бүлекнең оештырылган көненнән алып бүгенгә кадәр хезмәткәрләр тарафыннан китапханә эшчәнлегенең барлык өлкәләренә караган 1000 гә якын методик кулланма һәм тәкъдимле әдәбият исемлекләр төзелгән.

Методик эшнең тагын бер мөһим тармагы – республика китапханәчеләренең белемен өзлексез арттыру, аларның квалификациясен күтәрү. Шул максаттан чыгып семинарлар, җыелышлар, фәнни-практик конференцияләр үткәрелә, төбәк семинарлары да китапханәчеләргә зур ярдәм күрсәтә. Россия төбәкләрендә яшәүче татарларга хезмәт күрсәтүче китапханәчеләр дә әлеге чаралардан бик теләп файдаланалар.

Китапханә эшендәге яңалыкларны күзәтеп бару, белү һәм аны республика китапханәләренә җиткерү – бүлекнең тагын бер әһәмиятле бурычы. Хезмәткәрләр Татарстан Республикасы мәдәният министрлыгы грантларын караучы һәм тикшерүче экспертлар комиссиясе утырышларында актив катнашалар. Ел саен Татарстан Милли китапханәсе респуб-



других ведомств. Консультации проводятся по различным вопросам организации работы библиотек, в том числе по формам отчётности, проектной деятельности, работе с кадрами, нормативно-правовым вопросам, организации книжных фондов и методической работе.

Наиболее эффективной формой оказания методической помощи является разработка и издание методической литературы. За всю историю существования отдела его сотрудниками подготовлено около 1000 наименований методических пособий и рекомендаций по всем направлениям библиотечной деятельности.

Важнейшим направлением методической работы является организация системы непрерывного образования библиотечных работников республики. Прежде всего, это повышение квалификации библиотекарей, которое осуществляется посредством проведения семинаров, совещаний, научно-практических конференций. Также библиотекари обучаются по соответствующим программам в рамках дополнительного профессионального образования, организуются выездные зональные семинары. Большая работа проводится по обучению библиотекарей, работающих с татарским населением в регионах России и СНГ.

Выявление инноваций в библиотечном деле и внедрение их в практику библиотек республики – ещё одно важное направление работы научно-методического отдела. Его сотрудники регулярно участвуют в работе заседаний экспертной комиссии по рассмотрению и присуждению грантов Министерства культуры РТ. Ежегодно Национальной библиотекой РТ определяются лауреаты премии конкурсов «Лидер» и «Творческий



поиск» среди муниципальных библиотек республики. Премии учреждены в 2000 году Министерством культуры РТ в целях развития творческой и инновационной активности библиотечных работников, стимулирования их профессиональной деятельности, направленной на сохранение лучших традиций и развитие библиотечного дела республики. За время существования премий награду получили 14 централизованных библиотечных систем республики и 44 библиотеки разного уровня. Для многих муниципальных библиотек конкурсы стали своеобразной стартовой площадкой для развития инновационной деятельности.

Своеобразным брэндом, зародившимся в стенах Национальной библиотеки РТ в 1987 году, можно считать республиканский конкурс «Ел китабы» («Книга года»). Вот уже на протяжении 28-ми лет в ходе этого конкурса определяются самые популярные и читаемые книги, изданные в Татарстане, что вызывает живой интерес всей читающей общественности республики.

С 1993 года активно реализуется социологическая деятельность. В её задачи входит научно-исследовательская работа в области библиотечной социологии, поиск путей совершенствования деятельности и перспективного развития библиотеки. За эти годы проведено 9 полномасштабных социологических исследований и 12 социологических опросов локального характера. При этом основными направлениями социологической деятельности являются организация и совершенствование обслуживания через изучение пользователей как потребителей информации, изучение кадровых ресурсов библиотеки, изучение чтения, также активно разрабатываются вопросы взаимодействия Национальной библиотеки Татарстана и муниципальных библиотек республики.

Поиск новых, более действенных форм и методов работы, тесная связь с общественностью республики и регионами с компактным проживанием татарского населения характерны для работы научно-методического отдела – одного из важнейших и старейших подразделений Национальной библиотеки Республики Татарстан на современном этапе.

лика муниципаль китапханәләре арасында «Лидер» һәм «Иҗади эзләнү» конкурсларын үткәрә, лауреатларны билгели. Әлеге конкурслар һәм аларның премияләре 2000 елда ТР Мәдәният министрлыгы тарафыннан китапханәчеләрнең иҗади активлыгын арттыру, аларның һөнәри эшчәнлегенә этәргеч бирү, китапханә эшенең традицияләрен саклап, аны тагын да үстерү максатыннан чыгып гамәлгә куелды. Шушы вакыт аралыгында 14 Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы һәм 44 китапханә әлеге бүләккә ия булдылар.

1987 елдан бирле Татарстан Республикасы Милли китапханәсе тарафыннан «Ел китабы» дигән республика конкурсы үткәрелеп килә. 28 ел дәвамында Татарстанда басылган иң популяр, иң укыла торган китаплар билгеләнә, китап укучыларда һәм җәмәгатьчелектә китап укуга зур кызыксыну тудырыла.

1993 елдан социологик эшчәнлек алып барыла. Аның төп бурычы – китапханә социологиясе өлкәсендә фәнни-тикшеренү эше алып бару, аны тагын да камилләштерү юлларын эзләү. Шушы елларда 9 тулымасштаблы социологик тикшеренү һәм 12 локаль характердагы социологик сораштыру үткәрелгән.

Фәнни-методик бүлек хезмәткәрләре китапханәнең олуг юбилеен яңа эш алымнарын һәм кызыклы юнәлешләрне гамәлгә кертү омтылышы, республикабыз җәмәгатьчелеге һәм Татарстаннан читтә яшәүче татарлар белән элемтәләрне яхшырту теләге, эшкә иҗади караш, көч һәм дәрт белән каршылыйлар.

# ЧИТ ТЕЛЛӘРДӘГЕ ӘДӘБИЯТ БҮЛЕГЕ

# ОТДЕЛ ЛИТЕРАТУРЫ НА ИНОСТРАННЫХ ЯЗЫКАХ

Гыйльми хезмәткәрләрнең, белгечләрнең мәгълүмати ихтыяҗларын канәгатьләндерү, китапханә хезмәтләреннән файдаланучыларга чит телләр өйрәнүдә ярдәм итү максаты белән 1960 елда фәнни китап абонементы кысаларында чит телләрдәге китаплар белән эшләү бүлекчәсе төзелә. 1987 елда исә мөстәкыйль структур берәмлек – чит телләрдәге әдәбият бүлеге аерып чыгарыла.

Хәзерге көндә бүлек фонды дөньяның 50 телендәге 34 мең басманы үз эченә ала, алар төрле тармакларга – табигать фәннәренә, икътисадка, тарихка, хокук белеменә, медицинага һ.б. карый. Матур әдәбият әсәрләре дә, илләрне өйрәнү, тел белеме һәм сәнгать тә киң чагылыш тапкан. Файдаланучыларга Россиянең һәм чит илләрнең дөньядагы 10 телдә чыккан вакытлы матбугат басмалары тәкъдим ителә, газеталар һәм журналлар мәгълүмат тапшыруның һәм алуның мөһим чараларыннан санала бит. Чит телләрдәге матбугатны уку теге яки бу телдәге басма текстта ориентлашуны җиңеләйтеп кенә калмый, дөньяга карашны киңәйтә, күп халыкларның мәдәниятен һәм традицияләрен танып белергә мөмкинлек тудыра.

Чит телләр өйрәнү барышын күңелле һәм мавыктыргыч итәргә теләгәннәр өчен инглиз, алман, француз телләрендәге нәфис, мультипликацион, документаль фильмнар тупланмасы, компьютер аша укыту программалары бар.

ТР Милли китапханәсе җитәкчелегенең Гёте исемендәге Алман мәдәният үзәге белән хезмәттәшлеге кысаларында 2001 елның 9 ноябрендә чит телләрдәге әдәбият бүлегендә Алман уку залы ачылды. Аның ачылышы алман телен өйрәнү белән шөгыльләнүчеләр өчен чын бүләк булды. Залның Гёте исемендәге Алман мәдәният үзәге теләктәшлеге белән ел саен тулыланып торган фондында күпсанлы белешмә басмалар һәм монографияләр, классик һәм заманча матур әдәбият, төрле юнәлештәге газета һәм журналлар, алман музыкасы, нәфис һәм документаль фильмнар, экранлаштырылган театр спектакльләре яздырылган видео- һәм аудиоматериаллар бар.

В 1960 году в структуре абонемента научной книги с целью удовлетворения информационных потребностей научных работников, специалистов и в целях оказания помощи читателям в изучении и освоении иностранных языков был выделен отдел по работе с иностранной книгой. В 1987 году было выделено самостоятельное структурное подразделение библиотеки – отдел литературы на иностранных языках.



На сегодняшний день фонд отдела насчитывает более 34 000 документов на 50 языках мира по разным отраслям знаний: естественным наукам, экономике, истории, юриспруденции, медицине. Широко представлена художественная литература, а также литература по страноведению, языкознанию и искусству. Читателям предлагаются периодические издания российской и зарубежной прессы (на 10 языках мира), ведь газеты и журналы в современной жизни – важнейшее средство передачи информации. Чтение периодики на иностранных языках не только облегчает ориентацию в иноязычном печатном тексте, но и позволяет расширить кругозор, познать культуру и традиции многих народов.

Для тех, кто хочет сделать процесс изучения иностранных языков еще более приятным и увлекательным, предложена хорошая видеотека художествен-



Файдаланучылар өчен мәдәни һәм мәгърифәтчелеккә йөз тоткан чаралар үткәрү – бүлек эшчәнлегендәге мөһим юнәлеш. Алман уку залында алман язучылары һәм рәссамнары белән очрашулар уздырыла. Мәсәлән, Россиядә Алман теле һәм әдәбияты елында (2014/2015) Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә Алмания язучылары булды, алар Казан шәһәрендә яшәүчеләргә алман һәм рус телләрендә басылган әсәрләреннән өзекләр укыдылар, алман рәссамнары сәнгать һәм гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары өчен сәнгати мастер-класслар үткәрде.

Чит телләрдә аралашу клублары бүлек оешканнан алып бүгенгәчә уңышлы эшли. Тыңлаучылар һәм катнашучылар арасында студентлар, мәктәп укучылары гына түгел, өлкән яшьтәге кешеләр дә бар. Бу күренеш чит телләр өйрәнүгә ихтыяҗ барлыгын раслый. Чит телләрне өйрәнүче студентлар белән өч айга бер мәртәбә тематик очрашулар оештырыла, болар – нигездә, чит телләр өйрәтү методикасына һәм илләр өйрәнүгә багышланган дәресләр. Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балаларын махсус тел өйрәнү курсларына әти-әниләре алып килә. Иҗат итәргә яратучылар өчен бирудә «Кул эшләре остаханәсе» эшли, теләгән һәркем төрле илләрнең һәм халыкларның декоратив-куллама сәнгате белән таныша ала, хәтта үзе нәрсәдер ясап карарга да мөмкин.

Бүлекнең горурлыгы – «Мин – укучы» әдәби проекты. Аның максаты – үсеп килүче буында уку культурасын тәрбияләү һәм җәмгыятьтә китапның, укуның, китапханәнең дәрәҗәсен күтәрү. Проектны гамәлгә ашыру дәвамында мәктәп укучылары

ных, мультипликационных и документальных фильмов на английском, немецком и французском языках, компьютерные обучающие программы.

9 ноября 2001 года в рамках сотрудничества руководства Национальной библиотеки РТ и Немецкого культурного центра им. Гёте в структуре отдела литературы на иностранных языках был открыт Немецкий читальный зал. Его открытие стало настоящим подарком для тех, кто занимается изучением немецкого языка. Фонд зала, ежегодно пополняемый благодаря поддержке Немецкого культурного центра им. Гёте, представлен большим количеством справочных изданий и монографий, классической и современной художественной литературой, газетами и журналами разного направления, видео-, аудиоматериалами с записями немецкой музыки, художественными, документальными фильмами и экранизированными театральными постановками.

Проведение культурных и образовательных мероприятий для читателей – важное направление в деятельности отдела. В Немецком читальном зале проводятся встречи с немецкими писателями и художниками. Так, например, в рамках мероприятий Года немецкого языка и литературы в России (2014/2015) Национальную библиотеку Республики Татарстан посетили писатели из Германии, представив вниманию жителей г. Казани отрывки из своих произведений на немецком и русском языках, немецкие иллюстраторы провели для учеников художественных и общеобразовательных школ художественные мастер-классы.

Клубы общения на иностранных языках с носителями языка остаются актуальными с момента образования отдела и по сей день. Слушателями и участ-





өчен чит телләр әдәбиятына багышланган күзәтмә-мәгълүмати очрашулар циклы уза. Һәр очрашу – әсәр, аның авторы, автор яшәгән ил белән танышу. Аралашу (бергә тыңлау, кабатлау, рольләргә бүлеп уйнау, хәрәкәтле уеннар һ.б.) вакытында бала өчен күзәтү, тыңлау, чагыштыру мөмкинлекләре туа.

Әлеге очрашу-дәресләрдә күңелләрендә барлыкка килгән образларны, кәефне балалар рәсемгә төшерә, үзләре ясый торган аппликациядә, әвәләгән әйберләрендә чагылдыра. Иҗат белән шөгыльләнү баланың һәрьяклы үсешенә (акыл туплау, матурлыкны тоя белү, гәүдә өлешләренең хәрәкәтләнүе) ярдәм итә, шулай ук эчке тәэсир-күзаллауларны аңлата, шөгыльдән ләззәт ала белергә булыша.

2014/2015 уку елында бүлек хезмәткәрләре «Мин – укучы» проекты буенча кече яшьтәге мәктәп балалары белән актив эшләделәр. Уку елы ахырында проектта катнашкан балаларның әти-әниләреннән сораштыру үткәрелде. Нәтиҗәләр бик сөендерә: җавап бирүчеләрнең 99%-ы балаларының укуга, әдәби әсәрләргә карата кызыксынуы артуын, әдәбиятны дөрес сайлый башлауларын, уку һәм сөйләм техникасы камилләшүен билгеләгән. Әти-әниләр, дәресләр ахырында һәрвакыт иҗат өлеше булганга, ә иҗат бала өчен – табигый ихтыяҗ, анда бала күңеленең эчке тормышы чагыла, балаларының үз хисләре турында ешрак сөйләвен әйткән.

Чит телләр белү бервакытта да артык булмаган, хәзерге җәмгыятьтә ул аеруча кирәк. Моның аша хәтер дә ныгый, дөньяны тану да киңәя, шәхес күпьяклап үсә. Милли китапханәнең чит телләр әдәбияты бүлеге – бу кызыклы һәм мавыктыргыч юнәлештә ышанычлы ярдәмче.

никами выступают не только студенты и школьники, но и люди старшего поколения. Это говорит о том, что потребность в изучении иностранных языков есть. Каждый квартал устраиваются тематические встречи со студентами, изучающими иностранные языки – в основном это занятия по методике преподавания иностранных языков и страноведению. Увлеченные родители с удовольствием приводят своих чад на обучающие языковые курсы для детей дошкольного и младшего школьного возраста. Для любителей творчества в отделе проходят мастер-классы клуба «Лавка ручных работ», где любой желающий может познакомиться с декоративно-прикладным искусством разных стран и даже попробовать самостоятельно смастерить что-то сам.

Гордость отдела – это литературный проект «Я – читатель». Цель проекта – формирование культуры чтения среди подрастающего поколения и повышения престижа книги, чтения и библиотеки в обществе. Реализация проекта представляет собой цикл обзорно-информационных встреч для учащихся школ, посвященных зарубежной литературе. Каждая встреча – это знакомство с автором, его страной и произведением. В ходе общения (совместное слушание, повторение, разыгрывание по ролям, подвижные игры и др.) ребенок получает возможность наблюдать, слышать, сравнивать.

Знание иностранных языков давно не является излишеством, теперь изучение иностранного языка просто необходимо для современного общества. Это и прекрасное средство для тренировки памяти, расширения кругозора и всестороннего развития личности. Отдел литературы на иностранных языках – верный помощник в этом интересном, увлекательном процессе.



# СӘНГАТЬ БҮЛЕГЕ | ОТДЕЛ ИСКУССТВ

Бүлекнең тарихы онытылмас һәм мавыктыргыч вакыйгаларга бик бай. Кайберләрен хәзер әйтеп китәрбез.

Сәнгать бүлеге 1987 елда Казан шәһәре Үзәк китапханәсенең ноталар һәм музыка бүлегендә ачыла. Үз гомерендә бүлеккә 2 тапкыр урынын алыштырырга туры килә. Башта әлеге бүлек Казанның «Печән базары» мәчете бинасында урнаша (хәзер «Нурулла» мәчете, Мәскәү урамы, 74), аннан соң 1989-1999 елларда Карл Маркс урамында, 36 нчы йортта эшли, бүгенге адресы – Театр урамы, 5 нче йорт.





Н.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенә, И.Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллиятенә, М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрына, С.Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залына, В.Суриков исемендәге Мәскәү дәүләт академия сәнгать институтының Казан филиалына якын урнашуы студентлар, музыкантлар, сәнгать сөючеләр, сынлы сәнгать укытучылары өчен бик тә уңайлы булды, шуңадыр инде бүлек ел саен 1500 файдаланучыга хезмәт күрсәтә.

Бүлектә уку залы, музыкаль язмалар тыңлау өчен махсус урыннар, фильмнар һәм белем арттыру программалары бар, Интернеттан файдалану өчен барлык шартлар тудырылган.

История отдела богата яркими событиями и достижениями, о наиболее значимых из которых мы хотели бы рассказать.

Отдел искусств был создан в 1987 году на базе нотно-музыкального отдела Центральной библиотеки г. Казани. За время своего существования отдел дважды и очень удачно менял свое местоположение. Первоначально отдел искусств располагался в здании мечети «Сенного базара» (ныне – мечеть «Нурулла», ул. Московская, 74), затем, с 1989 по1999 гг., – ул. К. Маркса, д. 36, а с 1999 г. и по сегодняшний день – на ул. Театральной, д. 5.

Расположение в непосредственной близости от Казанской государственной консерватории им. Н. Жиганова, Казанского музыкального училища (колледжа) им. И. Аухадеева, Татарского государственного академического театра оперы и балета им. М. Джалиля, Большого концертного зала им. С. Сайдашева, Казанского филиала Московского академического художественного института им. В.И.Сурикова сделало отдел искусств чрезвычайно популярным среди студентов, музыкантов, учителей изобразительного искусства, музыки и любителей искусства. Отдел обслуживает более 1500 пользователей ежегодно.

Отдел искусств работает в режиме читального зала, имеет специально оборудованные места для прослушивания музыкальных записей, просмотра фильмов и образовательных программ, работы в Интернете.

Штат отдела искусств – 5 человек. За все годы существования отдела костяк сотрудников остается неизменным. Со дня основания и до октября 2013 года отдел искусств возглавляла Рудик Татьяна Никитична. Более 25 лет в отделе искусств трудятся Липачева Марина Вячеславовна (с 2015 года – заведующая отделом) и Мухаметзянова Альфия Махмутовна, 20 лет трудового стажа в отделе искусств у Артамоновой Елены Юрьевны. С 2010 года

Сәнгать бүлегендә 5 хезмәткәр эшли. Алар – үз эшләренең осталары. Бүлек ачылганнан алып 2013 елның октябренә кадәр коллективны Татьяна Никитична Рудик җитәкләде. 25 елдан артык бүлектә Липачева Марина Вячеславовна (2015 елдан – бүлек мөдире) һәм Мөхәммәтҗанова Әлфия Мәхмүт кызы хезмәт куялар. Елена Юрьевна Артамонованың да хезмәт стажы 20 ел. 2010 елда коллективка Малафеева Ольга Владимировна килде һәм тиз арада үз кеше булып китте һәм күптән түгел (2015 елныңмартында) безгә Ефимова Ирина Борисовна килеп кушылды.

Бүлекнең даими укучылары арасында Татарстан Республикасының күренекле сәнгать осталары, композиторлар, музыка белгечләре, Казандагы югары уку йортлары галимнәре һ.б. булулары белән без хаклы рәвештә горурланабыз. Күренекле артистлар Юрий Борисенко, Эмиль Җәләлетдинов, Юлия Җиһаншина, музыкантлар Юзефина Сокольская, Гүзәл Мөмәммәтдинова, музыка белгече Гүзәл Юнысовалар белән безнең бүлекне күпьеллык иҗади дуслык җепләре бәйли.

Сәнгать бүлегенең шәрәфле укучылары – композиторлар Леонид Любовский, музыка белгече Светлана Захарова, опера сөючеләр клубы президенты Ольга Иглина.

Китапханәнең кыйммәте һәм башкалар белән ярышырлык сәләте, иң беренче чиратта, аның фондлары составы белән билгеләнә. Бүлекнең китап фондын оештырганда Татарстан һәм татар халкының сәнгать тарихын чагылдырган документларга, классик һәм хәзерге заман сәнгатенә игътибар бирелә. Үзәк китапханәдән мирас булып нота һәм грампластинкалар гына калган булса, сәнгать бүлеге үзенең яшәү дәверендә фондларның санын күбәйтүгә ирешә, хәзер биредә 47000 документ саклана, алар арасында китаплар, ноталар, электрон басмалар, грампластинкалар бар.

Белешмә-библиографик эшчәнлек өлкәсендә бүлекнең зур казанышы булып Татарстан композиторлары иҗатына багышланган популяр электрон белешмәлекләр нәшер итү санала. Мәгълүмат-библиография һәм сәнгать бүлекләренең уртак проекты булган әлеге хезмәтләр Татарстан Республикасы Милли китапханәсендәге «Татарстан Республикасының күренекле мәдәният эшлеклеләре» дигән гомуми тупланманың бер өлеше буларак 2010–2015елларда эшләнеп, Татарстан Республикасы Милли китапханәсе сайтында урнаштырылды. Әлеге электрон белешмәлекләр Салих Сәйдәшев, Нәҗип Җиһанов, Рөстәм Яхин, Сара



органично влилась в коллектив Малафеева Ольга Владимировна, и совсем недавно (с марта 2015 года) работает Ефимова Ирина Борисовна.

Среди читателей – видные деятели искусства Республики Татарстан: композиторы, музыковеды, преподаватели творческих вузов г. Казани и многие другие. Многолетняя творческая дружба связывает отдел с певцами Эмилем Залядьдиновым, Юрием Борисенко, Юлией Зиганшиной, музыкантами Юзефиной Сокольской, Гузель Мухаметдиновой, музыковедом Гузель Юнусовой. Почетными читателями отдела искусств являются композиторы Леонид Любовский, музыковед Светлана Захарова, президент клуба любителей оперы Ольга Иглина.

Ценность и конкурентоспособность библиотеки определяются, в первую очередь, составом ее фондов. Приоритетными направлениями в формировании фондов отдела являются комплектование документами по истории искусства Татарстана и татарского народа, классическому и современному искусству. Унаследовав от Центральной библиотеки на этапе создания лишь ноты и грампластинки, отдел искусств за время своего развития увеличил численность фондов, и в настоящее время фонд составляет более 47 тыс. документов, среди которых – книги, ноты, электронные издания, грампластинки.

В справочно-библиографической деятельности большим достижением отдела искусств является выпуск популярных электронных справочников,



Садыйкова, Җәүдәт Фәйзи, Мансур Мозаффаров, Мирсәет Яруллин, Хөснулла Вәлиуллин, Рафаэль Белялов, Леонид Любовский иҗатларына багышланган.

Сәнгать бүлеге төзегән «Татарстанның музыкаль мирасы» (2010) дигән библиографик күрсәткеч тә күпьеллык фәнни эшчәнлекнең күркәм нәтиҗәсе. Аны милли музыкабызның ноталы басмалары репертуарын төзүнең нигезе дип санарга була. Библиографик күрсәткеч 1934–2000 елларда чыккан һәм Татарстан Республикасының иң эре китапханәләрендә саклانучы ноталы басмалар турында мәгълүматны үз эченә алган.

Сәнгать бүлеге эшчәнлегенең бер тармагы мәгърифәтчелеккә багышланган. Биредә китап һәм картина-рәсемнәр күргәзмәләре, музыкаль альбомнар премьералары, китап презентацияләре, музыкаль-тематик кичәләр, Мәгълүмат һәм Ачык ишекләр көннәре бик еш уздырыла.

«Театр кунакханәсе» Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары Әзһәр Шакиров, Ринат Таҗетдинов, Наил Дунаев, Ирек Баһманов, Нәҗибә Ихсанова, Равил Шәрәфиев, Хәлим Җәләлов, Фуат Әбүбәкеров һәм театрның яшь артистлары белән күпсанлы очрашулар үткәрде.

Без рәхәтләнеп милли мәдәниятебез тарихын өйрәнәбез, аңа кат-кат әйләнеп кайтабыз, чөнки үткәне юкның бүгенгесе дә бик сай, ә киләчәге бөтенләй юк.

посвященных творчеству композиторов Татарстана. Этот совместный проект информационно-библиографического отдела и отдела искусств – часть общей коллекции Национальной библиотеки Республики Татарстан «Выдающиеся деятели культуры Республики Татарстан». В 2010 – 2015 гг. были подготовлены и размещены на сайте Национальной библиотеки Республики Татарстан популярные электронные справочники, посвященные творчеству Салиха Сайдашева, Назиба Жиганова, Рустема Яхина, Сары Садыковой, Джаудата Файзи, Мансура Музафарова, Мирсаида Яруллина, Хуснуллы Валиуллина, Рафаэля Белялова, Леонида Любовского.

Результатом многолетней научной деятельности отдела искусств является выпуск библиографического указателя «Музыкальное наследие Татарстана» (2010 г.), который является основой репертуара национальных нот. Библиографический указатель содержит сведения о нотных изданиях, выпущенных в 1934-2000 гг., имеющихся в фондах крупнейших библиотек Республики Татарстан.

Важнейшим направлением деятельности отдела искусств является просветительская работа. На широкий читательский круг рассчитаны выставки книг и картин, различные обзоры, премьеры музыкальных альбомов, презентации книг, музыкально-тематические вечера, Дни информации, Дни открытых дверей и др.

«Театральная гостиная» провела цикл встреч на татарском языке с артистами Татарского государственного академического театра им. Г. Камала Азгаром Шакировым, Ринатом Тазетдиновым, Наилем Дунаевым, Иреком Багмановым, Нажибой Ихсановой, Равилем Шарафеевым, Халимом Заляловым, Фуатом Абубакировым и молодыми артистами театра.



Сотрудники отдела с удовольствием обращаются к истории, так как это помогает строить настоящее и воплощать мечты в будущем!

# ТЕРКӘҮ ҺӘМ СТАТИСТИКА БҮЛЕГЕ

Мөстәкыйль структур берәмлек буларак исәпкә алу секторы 1971 елдан бирле эшли, 1996 елдан исәпкә алу һәм тикшерү бүлекчәсе, 2000 елдан алып теркәү һәм статистика бүлеге дип атала.

Бүлекнең төп бурычлары:

– хезмәт күрсәткечләре статистик исәбенең тулылыгын һәм төгәллеген тәэмин итү;

– бердәм укучы билеты нигезендә китапханәдән файдаланучыларга уңай эш шартлары тудыру;

– фондның сакланышын тәэмин итү максатында китапханәдән файдалану кагыйдәләренең үтәлешен тикшерү;

– үзәкләштерелгән китапханәләр системаларына файдаланучылар белән эшнең исәбен алып баруда методик ярдәм күрсәтү.

Бүлекнең төзелеше:

– китапханәгә укучы итеп язу һәм җыелма статистик исәп төркеме;

– тикшерү төркеме.

Беренче төркем файдаланучыларны китапханәдән файдалану кагыйдәләре нигезендә китапханәгә укучы итеп яза һәм аларны яңадан терки. Яңа файдаланучыларны китапханә төзелеше, аннан файдалану кагыйдәләре белән таныштыра, китапханә күрсәтә торган хезмәтләр турында мәгълүмат бирә.

Тикшерү төркеме китапханәгә йөрүчеләрнең исәбен алып бара һәм кагыйдәләрнең үтәлешен тикшереп тора.

Бүлек статистик исәпне тәэмин итүдә катнашучы структур бүлекчәләрнең эшен координацияли, бүлекләрдә исәп эшенең куелышын тикшерүне оештыра, исәп документларын бердәм нормага китерә. Һәр квартал саен файдаланучыларга хезмәт күрсәтүче бүлекләрдән статистик мәгълүматлар җыя һәм аларны китапханә буенча гомумиләштерә.

Теркәү һәм статистика бүлеге катнашында файдаланучылар һәм китапханәгә йөрүчеләрнең тәкъдимнәре исәпкә алына, администрациягә җиткерелә; китапханәдән файдалану кагыйдәләренең үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрелә.



# ОТДЕЛ РЕГИСТРАЦИИ И СТАТИСТИКИ

Как самостоятельное структурное подразделение отдел под названием «сектор учета» существует с 1971 года, с 1996 года – сектор учета и контроля, с 2000 года – отдел регистрации и статистики.

Основные задачи отдела:

– обеспечение полноты и точности статистического учета показателей работы;

– создание комфортных условий работы пользователям библиотеки на основе единого читательского билета;

– осуществление контроля за соблюдением правил пользования библиотекой в целях обеспечения сохранности фонда;

